Министерство образования и науки Республики Татарстан
Муниципальное бюджетное учреждение дополнительного образования
«Дворец творчества детей и молодежи имени И.Х. Садыкова»
Нижнекамского муниципального района
Республики Татарстан

ПРИНЯТА
на заседании педагогического совета
МБУ ДО «ДТДиМ
им. И.Х. Садыкова» НМР РТ
Протокол № 1
от «31 » августа 2022 г.

УТВЕРЖДАЮ
Директор МБУ ДО «ДТДиМ
им. И.Х. Садыкова» НМР РТ
_____________ Р.Н. Салихзянов
Приказ № 211
от «31» августа 2022 г.

# ДОПОЛНИТЕЛЬНАЯ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНАЯ ОБЩЕРАЗВИВАЮЩАЯ ПРОГРАММА «Тел күрке- сүз»

***Направленность:*** художественная
***Возраст учащихся***: 11-15 лет
***Срок реализации***: 3 года (576 часов)

***Составитель:***
Зарипова Аниса Газизуловна,
педагог дополнительного образования

Нижнекамск, 2022 год

**Укыту программасының информацион картасы**

| | | |
|---|---|---|
| **1** | **Белем бирү оешмасы** | Өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенең “И.Х. Садыйков исемендәге Балалар һәм яшьләр иҗаты сарае” |
| **2** | **Программаның тулы исеме** | Тел күрке - сүз |
| **3** | **Программаның юнәлеше** | Сәнгати |
| **4** | **Программаны төзүчеләр турында мәгълүмат** | |
| 4.1 | Ф.И.О. | Зарипова Ә.Г., югары категорияле өстәмә белем бирү педагогы |
| **5** | **Программа турында мәгълүмат:** | |
| 5.1 | гамәлгә ашыру вакыты | 3 ел |
| 5.2 | укучыларның яше | 11-15 яшькә кадәр |
| 5.3 | программага характеристика:<br>-программаның тибы<br>-программаның төре<br>-программаны проектлау принциплары<br>-укыту процессын оештыру эчтәлеге формасы | Үстерелешле өстәмә гомуми белем бирү программасы<br>модификацияле<br><br><br>дәрес |
| 5.4 | программаның максаты | укучыларны халкыбызның үткәне, туган төбәгебез тарихы, татар әдәбияты нигезләре, сүз сәнгате, халык авыз иҗаты әсәрләре белән таныштыру, сәнгать әсәрләре аша – тормышка, дөньяга карашларын формалаштыру. |
| **6.** | **Белем бирү программасының формалары һәм алымнары** | Балалар берләшмәсе.<br>Проблемалы-эзләү ысуллары, мөстәкыйль һәм гамәли эшләр, төрле дәрәҗәдәге бәйгеләр |
| **7.** | **Нәтиҗәлелекне мониторинглау формалары** | иҗади эш, тестлар, биремнәр, кичәләр, бәйгеләр, реферат яклау |
| **8.** | **Программаның нәтиҗәлелеген тормышка ашыру** | Программаның әһәмиятле конкурсларда катнашу нәтиҗәләре һөнәри осталык белән конкурсны оештыручы күрсәтмәсе һәм вакыты<br>Туган тедә белем бирүче хезмәткәрләрнең Татарстан республикасы территориясендә яшәүче халыкларның телләрен саклау һәм үстерүгә юнәлдерелгән проект эшчәнлеген тормышка ашыру буенча республикакүләм конкуста җиңүче. 2022 нче ел |
| **9.** | **Программаны раслау һәм** | 31.08.2022 нче ел |

| | | |
|---|---|---|
| | **соңгы үзгәртү датасы** | |
| **10.** | **Рецензентлар** | Зиновьева Ф.М. – методист |

**Эчтәлек**


1. Аңлатма ………………………………………………………........................................ 4-9
2. Укыту планы
1нче ел…………………………………………………….................................... 9-10
2нче ел.........................................................................................................................12
3нче ел.....................................................................................................................14-15
3. Программаның эчтәлеге
1нче ел…………………………………………………….....................................10-12
2нче ел.....................................................................................................................13-14
3нче ел.....................................................................................................................15-16
4.Программаның педагогик-оештыру шартларын тормышка ашыру.....................17-39
5. Кулланма әсбаплар.................................................................................................39-40
6. Кушымта.
Кушымта 1. Методик материаллар…………………………………………41-56
Кушымта 2. Календарь-укыту тәртибе……………………………….......57-84
Кушымта 3. “И.Х. Садыйков исемендәге Балалар һәм яшьләр иҗаты сарае” өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенең тәрбия программасын тормышка ашыру буенча тәрбия эше планы...........................................................85-90

## АҢЛАТМА ЯЗУЫ

“Тел- күрке – сүз” - сәнгать юнәлешендәге программа**.**

Программаны норматив-хокукый тәэмин итү. Программа төп норматив документлар нигезендә эшләнде:

- Бала хокуклары турында БМО конвенциясе;
- Россия Федерациясендә мәгариф турында Федераль закон 29.12.2012 №273-ФЗ;
- Балаларга өстәмә белем бирүне үстерү концепциясе 31.03.2022 № 678-р;
- Стратегик үсеш һәм милли проектлар буенча Россия Федерациясе Президенты каршындагы Совет президиумы утырышы беркетмәсе белән расланган «Һәр баланың уңышы» Федераль проекты 3.09.2018 № 10;
- “Балаларга өстәмә белем бирүнең төбәк системаларын үстерүнең максатчан моделен раслау турында" 3.09.2019 №467 Россия Мәгариф министрлыгы боерыгы;
- Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының «Өстәмә гомуми белем программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 9.11.2018 №196 боерыгы;
- «Мәгариф программаларын гамәлгә ашырганда белем бирү эшчәнлеген, электрон укытуны, дистанцион белем бирү технологияләрен гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан куллану тәртибен раслау турында» 23.08.2017 № 816 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы;
- СП 2.4. 3648-20 " санитар-эпидемиологик таләпләр. “Балаларга һәм яшьләргә тәрбия бирү, ял итү һәм сәламәтләндерү оешмаларына" Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының 28.09.2020 ел, №28 карары белән расланган;
- Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының “И. Х. Садыйков исемендәге балалар һәм яшьләр иҗаты Сарае " өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе уставы;
- Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы “И Х. Садыйков исемендәге балалар һәм яшьләр иҗаты Сарае" өстәмә гомуми белем бирү программасын эшләү һәм раслау турында нигезләмә.

*Программаның актуальлеге.*

Татарлар күп гасырлар буена әдәбиятлы һәм китаплы халык. Татар телендә борын-борыннан берсеннән-берсе гүзәл әдәби әсәрләр иҗат ителеп киленгән. Бигрәк тә шигъри әсәрләрнең аһәңле, ягымлы һәм төрле сурәтләргә бай теленә без сокланып туймыйбыз. Чәчмә һәм драма әсәрләре дә телебезнең киң мөмкинлекләре ярдәмендә шигърият дәрәҗәсенә күтәрелә баралар. Телебез халыклар арасында аралашу коралы буларак та даими файдаланып киленгән. Бу телдә фәлсәфи, тарихи, хокукый һәм фәннең башка өлкәләренә караган хезмәтләр дә язылган. Күрәбез, язма тел мәдәниятебез шактый югары дәрәҗәгә ирешкән. Әмма кешеләр телне иң әүвәл сөйләмдә, бер-берләре белән гадәти аралашуда кулланалар. Кызганычка каршы,

нәкъ менә шушы өлкәдә – җанлы сөйләмдә телебезнең матур яңгырашын саклауга, аның хисси, тасвирый һәм тәэсирлелек көчен арттыруга җитәрлек игътибар бирелми. Еллар узган саен, сөйләм бары тик нәрсәне дә булса хәбәр итү чарасы булып кына кала бара. Әлбәттә, бу телнең ярлылануына китерә. Укучыларны сөйләмнең мәгънәви ягына игътибарлы булырга өйрәтү белән бергә, аларның бер үк вакытта әйтелгәннәргә бәрабәр хис-кичерешләрен, мөнәсәбәтләрен дә җиткерергә күнектерү – укытучыларның төп бурычларыннан берсе.

*Педагогик максатчанлык*

Өстәмә белем бирү программасы укучыларның белем алу, иҗади сәләтләрен ачыклау, үстерү өчен тиешле мохит булдыру һәм укучыларның иҗади мөминлекләрен ачу белән беррәттән кешелеклелек , әхлак сыйфатлары тәрбияләүне максат итеп куйды

*Башка программалардан үзгәлеге.*

Өстәмә белем бирү программасы буларак, ул мәктәп программасын җиңел үзләштерүче балалар өчен дә, программаны авыр үзләштерүчеләр өчен дә исәпләнгән. Программаның өстенлеге шунда – ул укучыларга татар әдәби телен, сүз сәнгате серләрен өйрәтү аспектларын да күзаллый.

*Укучыларга дистанцион ярдәм күрсәту формалары*

Программаны тормышка ашырганда мәгълүмати һәм компьютер технологияләре, шулай ук дистанцион укыту формалары актав кулланыла. Алынган белемнәрне ныгыту, гамәли күнекмәләрне камилләштерү өчен сайтлар белән дистанцион хезмәттәшлек алып барыла*:*

1. https//tatarica.org/ru/razdely/nauka/nauchnye-obshestya/obshestvo-izucheniya-tatarctana;
2. Образовательная платформа «ZOOM»;
3. tatarmultfilm.ru;
4. kinodeti.tv;
5. m.vk.com/teatralts;
6. ***posleurokov.ru***

**ПРОГРАММАНЫҢ МАКСАТЫ**

Тел гыйлеме, тарихыбызны, халык авыз иҗаты әсәрләре үрнәкләрен өйрәнеп, укучыларның интеллект дәрәҗәсен үстерү, тормышка яраклашкан (социальләшкән) шәхес тәрбияләү. Кеше тормышында сүз сәнгатенең гаять әһәмиятле роль уйнавын аңлату; фикерне аңлашлы, күңелдәге хисне матур итеп әйтеп бирә белергә, дөрес сөйләшергә өйрәнү; укучыларда әхлакый зәвык тәрбияләү.

**ПРОГРАММАНЫҢ БУРЫЧЛАРЫ**

*белем бирү* :

- сөйләм культурасын үстерү, әдәби тел нормаларын белергә,
- дикция өстендә һәрдаим эшләргә өйрәтү;
- тарихи үткән юлыбыз, халык авыз иҗаты турында мәгълүматлы булу;

*үстерү:*

- әдәби телдә сөйләм һәм язма тел байлыкларын үстерү,

- чыгыш ясау, аралашуга өйрәтү,
- төрле стиль һәм жанрдагы текстлар төзү күнекмәсе формалаштыру, укучыга үзенең сөйләм осталыгын, талантын сынап карарга шартлар тудыру.

*тәрбия бирү*:

- укучыларда халкыбызның сүз сәнгатен;
- тарихын, халык авыз иҗатын өйрәнәсе килү теләге булдыру;
- укучының үзаңын үстерү, милләтне, ватанны яратырга өйрәтү;
- милли горурлык һәм гражданлык хисләре тәрбияләү;
- шәхеснең әхлакый-рухи сыйфатларын камилләштерү.

*Программаны тормышка ашыруда катнашучы балаларның яше:*

Программа 5-8 нче сыйныфта укучы 11-15 яшьтәге балалар өчен тәкъдим ителә. Берләшмәгә теләк белән килгән кызлар һәм малайлар алына.

*Программныңа күләме* 576 *сәгать.* Беренче ел укыту сәгате – 144 сәгать, икенче, өченче ел укыту - 216 сәгать тәшкил итә.

*Дәресне оештыру формалары.*

Прграммада укыту формасы буенча эш фронталь, индивидуаль, парлап-парлап, звенолап һәм төркемләп оештырылырга мөмкин, ләкин ул ничек оештырылса да, коллектив эчендә шәхесара мөнәсәбәтләр тәрбияләүгә ярдәм итәрлек булырга тиеш.

Фронталь формада укыту материалны бөтен коллективка бирү юлы булса, звенолап һәм төркем белән эшләү юлында укучыларга сәләтләрен ачарга, бер-берсенең ярдәмен тоярга һәр конкрет этапта мөмкинлекләр туа.

Укучыларның укыту һәм тәрбия ихтыяҗларын үзенчәлекле итү өчен төркемнәр һәм төркемчекләр белән эшләү тәкъдим ителә (баланың яше һәм берләшмәдә эшләү тәҗрибәсе күздә тотыла). Индивидуаль форма укучының мөстәкыйль рәвештә шөгыльләнүен искәртә. Монда педагог ярдәме белән баланың эшчәнлеге арта, ул мөстәкыйль эшләргә өйрәнә. Дәресләрнең эчтәлеге дифференциаль яктан балалар һәм яшүсмерләрнең яшен исәптә тотып билгеләнә. Аларда балаларның индивидуаль иҗади үсеше өчен барлык шартлар чагыла. Теоретик һәм практик дәресләр, күрсәтмә материаллар (этголингвистик материаллар, таблицалар, схемалар, альбомнар, карточкалар, видеосюжетлар, презентацияләр)

- типовой дәресләр (үз эченә теоретик нигез белән танышу һәм теоретик нигезне ныгыту өчен кирәк булган күнегү һәм уеннарны ала);
- иҗади дәресләр (презентацияләр, хикәяләр, проектлар төзү, видео язмалар булдыру һ.б.);
- практик дәресләр;
- видеоматериаллар карау;
- сюжетлы-уенлы һәм бәйге программалары;
- иҗади эшләрне яклау

*Программаны үзләштерү вакыты* - 3 ел.

Программа өч ел укытылуга язылган. Берләшмәдә укыту даими составта, төркемләп алып барыла. Беренче ел укытылучы балалар саны – 15, икенче ел укытылучылар саны - 12, өченче ел укытылучылар саны – 10.

*Дәрес режимы*

Программа буенча урта сыйныф укучылары шөгыльләнә ала. Беренче ел укытылучы балалар атнага 2 көн 2шәр сәгать, икенче, өченче ел укытылучы балалар атнага 2 көн 3әр сәгать белем алалар. Укыту укучылар сәламәтлегенә зыян килми торган җылы, якты һәм уңайлы бүлмәләрдә алып барыла. Берләшмәдә укыту даими составта, төркемләп алып барыла.

***Программаны үзләштерүдә көтелгән нәтиҗәләр***

*Беренче ел укыту*

<u>*Метапредмет күрсәткечләре*</u>

- *иҗади бурычны аңлау;*
- *өстәмә әдәбият, төрле мәгълүмат чыганаклары белән эшләү;*
- *эзлеклелекне саклау;*
- *индивидуаль, төркемдә эшләргә;*
- *эшчәнлек нәтиҗәләрен рәсмиләштерү.*

<u>*Шәхси күрсәткечләр*</u>

- укучының җаваплылык хисен активлаштыру;
- укуга һәм хезмәткә уңай мөнәсәбәт булдыру;
- баланың үзаңын үстерү, милләтне, ватанны яратырга өйрәтү, горурлык һәм гражданлык хисләре тәрбияләү;
- төрле чыганаклардан (сүзлекләр, энциклопедияләр, интернет-ресурслар һ.б.) танып-белү һәм коммуникатив ихтыяҗларны канәгатьләндерерлек мәгълүматлар табарга күнектерү;
- әңгәмәдәшеңнең сөйләмен тыңлап аңлау һәм аларга үз фикереңне аңлата белү, алар белән әңгәмә кору, әңгәмәдә катнаша белү;

<u>*Предмет күрсәткечләре*</u>

*Беренче ел уку ахырына укучы беләчәк*:

- - иҗади бурычны аңлый;
- эзлеклелекне саклый;
- индивидуаль, төркемдә эшли belә;

*булдырачак:*

- эшчәнлек нәтиҗәләрен рәсмиләштерә;
- өстәмә әдәбият, төрле мәгълүмат чыганаклары белән эшли.

*Икенче ел укыту*

<u>*Метапредмет күрсәткечләре*</u>

- алынган белем – мәгълүматларны камилләштерү, киңәйтү, бер системага салу, башка фәннәрдә дә куллана белү;
- эш тәртибен аңлап уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү;

- куелган проблемаланы табу һәм чишә белү.

<u>*Шәхси күрсәткечләр*</u>

- куелган проблемаланы таба һәм чишә белә;
- куелган максатка ирешүдә ихтыяр көчен күрсәтә,
- төркемдә эшләү күнекмәләренә ия;
- сәламәтлекнең көчен һәм бәясен аңлый;
- өстәмә материаллар, төрле чыганаклар белән эшли белә;
- уңышка ирешү юлларын күзаллый.

<u>*Предмет күрсәткечләре*</u>

*икенче ел уку ахырына укучы беләчәк*:

- текст (тезмә, чәчмә) өстендә эшли белә;
- төрле стиль һәм жанрдагы текстлар төзү күнекмәсе формалаштыра*;*

*булдырачак:*

- сәнгатьле сөйләм осталыгын үстерә, сүзлек байлыгын арттыра;
- чыгыш ясый, аралаша.

*Өченче ел укыту*

<u>*Метапредмет күрсәткечләре*</u>

- тормышта үзеңнең тоткан урыныңны билгеләү;
- актив позициягә омтылу;
- тел курсының һәр бүлеген өйрәнгәндә, татар телен өйрәнүнең практик әһәмиятен ассызыкларга, туган телнең байлыгын, матурлыгын, сүзләрнең төрле яңгырашын, бер үк сүзнең яңа бизәк алганын күрсәтү өстендә эшли белү.

<u>*Шәхси күрсәткечләр*</u>

- фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә, шулай ук, реаль тормышта туган проблемаларны хәл итү өчен кирәк булган универсаль уку гамәлләрен (танып белү, регулятив, коммуникатив) формалаштыруга хезмәт итү;
- шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда татар теленә карата ихтирамлы караш.

<u>*Предмет күрсәткечләре*</u>

*өченче ел уку ахырына укучы беләчәк*:

- әдәби әсәрләрне аңлы һәм сәнгатьле укый белә, укыганны телдән сурәтләп бирә ала, аңлата ала, шигъри текстларны яисә чәчмә әсәрдән өзекләрне сайлап алып (яки тәкъдим ителгән) яттан сөйли;
- тел гыйлеме, тарихыбызны, халык авыз иҗаты әсәрләре үрнәкләрен белә;
- диалог, монолог төзүнең үзенчәлекләрен аера;
- сәхнәдә үзен иркен тота, тамашачы каршында дулкынламый чыгыш ясый;

*булдырачак:*

- фәнни - гамәли конференцияләрдә, сәнгатьле сөйләм бәйгеләрендә чыгыш ясау күнекмәләрен тулысынча үзләштерә;
- фикерне аңлашлы, күңелдәге хисне матур итеп әйтеп бирә белә;

- төрле мәгълүмат чаралары белән эшли, кирәкле мәгълүматны таба, анализлый һәм үз эшчәнлегендә куллана белә.

Программаны үзләштерү коммуникатив һәм гуманлылык кебек асыл сыйфатларга ия булган, халкыбыз традицияләрен хөрмәт итүче, дөньяны камил итеп танып белергә омтылучан, мәдәниятыбызны баетырга сәләтле, һәрдаим үз өстендә эшләүче максатчан, актив иҗади шәхес формалаштыруны күз алдында тота. Программа татар телен өйрәнүнең практик әһәмиятен ассызыкларга, укучыларга туган телнең байлыгын, матурлыгын, сүзләрнең төрле яңгырашын, бер үк сүзнең яңа бизәк алганын күрсәтү өстендә эш алып барыла

*Программаны тормышка ашыруны тәэмин итүче нәтиҗә формалары*

Укыту процессы түбәндәге тикшерү ысулларын күздә тота*:*

а) кереш - әңгәмә, сораштыру, тестлар эшләү (уку елы башында үткәрелә, үткән темалар буенча белем һәм күнекмәләрне ныгыту өчен);

б) агымдагы – практик эш, биремнәр, төрле кичәләрдә катнашу, район, республика күләмендәге бәйгеләрдә, фестивальлләрдә, конкурсларда чыгыш ясау;

в) арадаш тикшерү – тестлар эшләү;

д) йомгаклау (уку-укыту программасын бетергәннән соң) – йомгаклау чыгышы.

Йомгаклау аттестациясен уңышлы үткән чыгарылыш укучыларына "Тел күрке – сүз” өстәмә гомуми белем бирү программасын үзләштерү турында таныклык бирелә.

## 1 ЕЛ УКЫТУГА УКУ ПЛАНЫ

| № | Тема | Барлык сәгать | Теория | Практика | Аттестация формалары |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Кереш дәрес | *2* | *2* | - | Әңгәмә, сораштыру |
| 2. | Туган телем- татар теле | 10 | 5 | 5 | Аралашу |
| 3. | Татар теленең сүз байлыгы хәзинәсе | 8 | 5 | 3 | Үзлектән эш |
| 4. | Татар орфографиясенең кыен очраклары | 8 | 4 | 4 | Хаталарны төзәтү |
| 5. | Сәнгатьле сөйләм күнекмәләре | 8 | 4 | 4 | Мини - тест |
| 6. | Аралашу әдәбе. Телдән яки язма аралашу | 20 | 5 | 15 | Иҗади бәйге |
| 7. | Иҗади күнегүләр. Тәрҗемә эше белән шөгыльләнү | 16 | - | 16 | Карточкалар белән эш |
| 8. | Хәзерге заман эшлекле татар теле | 14 | 5 | 9 | Үзлектән эш |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 9. | Татар халык иҗаты. Аның жанрлары | 38 | 16 | 22 | Иҗади эш |
| 10. | Татар балалар язучылары | 18 | 5 | 13 | Аралашу |
| 11 | Йомгаклау | 2 | 2 | | Иҗади эш |
| | Барлык сәгать: | 144 | 67 | 77 | |

## *1 ЕЛ УКЫТУГА ПРОГРАММА ЭЧТӘЛЕГЕ*

**1 тема**. **Кереш дәрес.** Укучыларны түгәрәккә туплау, максат һәм бурычлар, планнар белән таныштыру, инструктажлар үткәрү. Хезмәт иминлеге кагыйдәләрен өйрәнү. Юл йөрү кагыйдәләре буенча әңгәмә*. **Кереш - әңгәмә, сораштыру, тестлар эшләү.***

Күрсәтмә материал: Обучение школьников правилам безопасного поведения на дороге (5-9 классы): Учебно-методическое пособие / Р.Ш.Ахмадиева, С.А.Бикчентаева, Д.Д.Забиров, Е.Е.Воронина и др./ Под общей ред. Р.Н.Минниханова, Д.М.Мустафина. – Казань: ГБУ «НЦ БЖД», 2013 г.

**2 тема. Туган телем- татар теле.**

Максат. Тел ул – халыкларның иң әһәмиятле аралашу чарасы булуын аңлату.

Татар телендәге сузык һәм тартык авазларга өлешчә характеристика бирә белү. Сузык һәм тартыкларга карата кагыйдәләрне гамәли куллана белү күнекмәсе булдыру. ***Өйрәнелгән материал буенча телдән сораштыру***

Җиһазлау. Н.В.Максимов, С.М.Трофимова, М.З.Хәмидуллина - Татар теленнән дидактик материаллар (5-7 нче сыйныфлар) – Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2000 “Идел”, “Казан”, “Мирас” журналары, аңлатмалы, тәрҗемәи сүзлекләр, энциклопедияләр, альбомнар, аудио – видеокассеталар, ноутбук, интерактив такта, видеомагнитофон.

**3 тема. Татар теленең сүз байлыгы хәзинәсе.**

Максат. Сүзләрнең мәгънәләре. синоним, омоним, антоним сүзләр, аларның тармаклары, фразеологизмнар, күпмәгънәле сүзләр, алынма сүзлә, архаизмнар, неологизмнар бүлекләре буенча алган белемнәрне гамәлдә куллану күнекмәләре булу. ***Өйрәнелгән материал буенча телдән сораштыру***

Җиһазлау. Зарипова, Г.Г. З-26 Татарский язык. Культура речи : учебно-методическое пособие / Г.Г. Зарипова, Б.М. Мирдиянова. – Нижнекамск : Нижнекамский химико-технологический институт (филиал) ФГБОУ ВПО «КНИТУ», 2013. – 60 с. Ноутбук, интерактив такта

**4 тема. Татар орфографиясенең кыен очраклары**

Максат. Әйтелеше белән язылышы арасында аерма булмаган сүзләрне ишетеп яза белү. Тел берәмлекләрен танып, аларны тикшерә, рус теле белән чагыштыра алу һәм аралашуда урынлы куллану күнекмәләрен камилләштерү. Күрсәтмә такталардан орфографик яктан хаталы язылган сүзләрне барлау*. **Хаталы элмә такталарын барлау һәм сүзләрнең дөрес язылышын өйрәнү***

**5 тема. Сәнгатьле сөйләм күнекмәләре.**

Максат. Тел байлыгын үстерү. Сәнгатьле сөйләм күнекмәләре өстендә эшчәнлек алып бару. ***Сүзләрнең әйтелеше өстендә эш***.

Җиһазлау. Хәйруллина А.Х. Дөрес сөйләргә өйрәнегез.- Казан:Казан нәшр.,1992.-96б., Рәүф Нуриев Сәнгатьле уку. Методик ярдәмлек. -Казан.-2000.-152б., Курбатов Х.Р. Сүз сәнгате: Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы. -Казан: Мәгариф, 2002.-199б., Галимуллин Т.Н.Хәзерге шигърият// Мирас-1996.-№7-8, темага кагылышлы альбомнар, аудио – видеокассеталар, мәкаләләр, ноутбук, интерактив такта, видеомагнитофон.

**6 тема. Аралашу әдәбе.** Телдән яки язма аралашу.

Максат. Аралашу әдәбенә, чыгыш ясарга өйрәтү; аралашу үзенчәлекләрен, жанр төрләрен, формаларын төшендерү; аралашуның инновацион формаларына өйрәтү.***Үзара дөрес аралашу әдәбен ныгыту***

Җиһазлау.

1.Абдуллина Р.С. Риторика һәм интонация. Монография. – Яр Чаллы, 1999

2. Габдулхаков В.Ф. Риторика 9. – Казань: Магариф, 2004

3. ИбраһимоваФ.И. Балалар әдәбияты: Хрестоматия – Казан: Магариф, 2004

4. Косхтев Н.Н. Риторика 8-9 – Москва: Просвещение, 1997

5. Михальская А.К. Основы риторики 10-11 - Москва: Просвещение, 1996

6. Низамов И.М. Уем – тел очында – Казан: Тат. кит. нәшр., 1995

7. Нуриев Р. Сәнгатьле уку. Методик ярдәмлек – Казан, 2000, альбомнар, аудио – видеокассеталар, шагыйрьләрнең җыентыклары, ноутбук, интерактив такта, видеомагнитофон.

**7 тема. Иҗади күнегүләр. Тәрҗемә эше белән шөгыльләнү**.

Максат. Лирик шигырьләрне прозага әйләндерү.

Эпитет, гипербола, метонимия, метафора, сынландыру кебек сурәтләү чараларыннаң әһәмиятен ассоциатив формаларда әдәби әсәрләрдә кулланышын аңлау һәм кулланырга өйрәтү. ***Тәрҗемә эше белән шөгыльләнү, иҗади күнегүләр башкару***.

Җиһазлау. Рус телендәге җыр, хикәя, шигырь, әкият һәм очеркларны стилистик яктан дөрес итеп татар теленә тәрҗемә иткән үрнәкләр. Сүзлекләр, энцилопедияләр, тематик календарьлар, журналлар, ноутбук, интерактив такта, видеомагнитофон.

**8 тема. Хәзерге заман эшлекле татар теле**

Максат. Эш кәгазьләрен татар телендә язарга өйрәтү; көндәлек һәм профессиональ аралашу этикетына лексика туплау; сүзлек өстендә эшләүне камилләштерү, яңа өйрәнелгән сүзләрне эшлекле сөйләшүләр барышында, аралашканда куллана белү. ***Эш кәгазьләрен язу.***

Җиһазлау. Вәлиуллина Р.Г., Хөсәенова Р.Н. Эшлекле татар теле. – Казан, 2004, Вәлиев З.В. Эш кәгазьләре үрнәкләре. – Казан, 1999, ноутбук, интерактив такта, видеомагнитофон.

**9 тема. Татар халык иҗаты. Аның жанрлары**

*Максат*. Такмаклар,табышмаклар, сынамышлар, санамышлар, тизәйткечләр, мәкаль һәм әйтемнәр, әкиятләр, татар халык җырларын өйрәнү. ***Сүз турында мәкаль, әйтемнәр туплау.***

*Җиһазлау.* Татар халык әкиятләре 1 – 5 томнар, альбомнар, аудиокассеталар

**10 тема: Татар балалар язучылары**

Максат. Укучыларны иҗади хезмәткә тарту: язучыларның балалар өчен язган шигырьләре нигезендә үзләре дә шигырь язып карауларын оештыру һәм матбугатка җиткерү. ***Матбугат материалларына күзәтү ясау***.

*Җиһазлау.*Татар балалар әдәбияты: Әкиятләр һәм хикәяләр. – Казан: Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшрияты, 2003. Татар балалар әдәбияты: Шигырьләр һәм пьесалар. – Казан: Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшрияты, 2003. Хәзерге балалар шигърияты. – Казан: Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшрияты, 2004.

**11 тема: йомгаклау дәресе.**

Максат: түгәрәк эшчәнлегенең еллык эшенә нәтиҗә ясау.

Еллык эшебезгә нәтиҗә ясау. Нинди уңышларга ирештек. Фикерләр алышу. Алдагы уку елына планнар. Юл йөрү кагыйдәләрен кабатлау. ***Тест эшләү.***

## 2 ЕЛ УКЫТУГА УКУ ПЛАНЫ

| № | Тема | Барлык сәгать | Теория | Практика | Аттестация формалары |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Кереш дәрес. Куркынычсызлык кагыйдәләре бәлән танышу | 3 | 3 | - | тест |
| 2. | Татар халкының йолалары | 3 | 2 | 1 | аралашу |
| 3. | Балалар фольклоры | 15 | 5 | 10 | Мини - тест |
| 4. | Татарстан- минем республикам | 36 | 2 | 38 | Үзлектән эш |
| 5. | К. Насыйриның педагогик эшчәнлеге | 6 | 4 | - | Карточкалар белән эш |
| 6. | Иҗади күнегүләр Тәрҗемә эше белән шөгыльләнү | 18 | 4 | 10 | Иҗади бәйге |
| 7. | Тел – матурлык ачкычы | 12 | 10 | 4 | Әңгәмә |
| 8. | Халкыбызның күңел бизәкләре – кул эшләре | 48 | 6 | 42 | Тест |
| 9. | Түбән Кама- туган төбәгем | 36 | 10 | 24 | Карточкалар белән эш |
| 10. | Гаилә тарихы-халкыбыз тарихы | 36 | 10 | 26 | Иҗади эш, тест сораулары |
| 11. | Йомгаклау | 2 | 2 | | Иҗади эш |
| | Барлык сәгать: | 216 | 58 | 158 | |

## 2 ЕЛ УКЫТУГА ПРОГРАММА ЭЧТӘЛЕГЕ

**1 тема**. **Кереш дәрес.** Түгәрәкнең планы, максаты белән танышу. Хезмәт иминлеге кагыйдәләрен өйрәнү. Юл йөрү кагыйдәләре буенча әңгәмә. ***Кереш контроль эш.***
*Күрсәтмә материал*: Обучение школьников правилам безопасного поведения на дороге (5-9 классы): Учебно-методическое пособие / Р.Ш.Ахмадиева, С.А.Бикчентаева, Д.Д.Забиров, Е.Е.Воронина и др./ Под общей ред. Р.Н.Минниханова, Д.М.Мустафина. – Казань: ГБУ «НЦ БЖД», 2013 г

**2 тема**. **Татар халкының йолалары.**
*Максат.* Укучыларны милли-мәдәни рухта тәрбияләгәндә татар халкының электән килгән гореф-гадәтләре , мәдәнияте белән кызыксынучы югары әхлаклы, һәряклап үсеш алган, иҗади шәхес тәрбияләү өчен шартлар тудыру. ***Өйрәнелгән материал буенча телдән сораштыру***
*Җиһазлау*. Уразман Р. Татар халкының йолалары һәм бәйрәмнәре / Татарсан Милли к-ханәсе; Төз.З.Ә.Җамалиева. Казан: милли китап, 2000, Баязитова Ф. Татар халкының бәйрәм һәм көнкүреш йолалары.- Казан: Татар кит.нәшр., 1995

**3 тема. Татар балалар фольклоры.**
*Максат.* Багу поэзиясе, күңел ачу фольклоры, уен фольклоры, сынамышлар, әйтешләр, алдавычлар, эндәшләр, юаткычлар, мавыктыргычлар, тизәйткечләр, шаярулар белән танышу, аларны өйрәнү. Ш. Галиев иҗаты белән танышу. ***Түгәрәккә йөрүче балаларның тизәйткечләрдән рифмадаш сүзләр табып үз шигырьләрен иҗат итүгә юнәлеш бирү, ритмик яңгыраш өстендә эшләү.***
*Җиһазлау*. «Татар балалар фольклоры», Татар энциклопедиясе, карточкалар, папкаларга тупланган материаллар, фотографияләр, рәсемнәр «Салават күпере», «Сабыйга», «Ялкын», «Сабантуй, “Балалар фольклоры “китабы, газеталардан материаллар журналлар.

**4 тема**. **Татарстан- минем республикам**.
*Максат*. Татарстан республикасының символикалары, тарихи урыннары, Казан- чал тарихлы башкала, Шәһри Болгар турында белемнәрен тирәнәйтү. ***“Татарстан- минем республикам” темасына күргәзмә эшләү.***
*Җиһазлау.* ”Татарстан” журналы, 2005 ел, №10, ”Ватаным Татарстан” газеты, 2008 ел, май.

**5 тема**. **К. Насыйриның педагогик эшчәнлеге.**
*Максат*. К. Насыйриның педагогик эшчәнлеге белән якыннан танышу. ***Тест биремнәре башкару.*** *Җиһазлау.*Татар әдәбияты тарихы, К.Насыйри портреты, аның турында мәкаләләр.

**6 тема. Иҗади күнегүләр. Тәрҗемә эше белән шөгыльләнү**
*Максат.* Лирик шигырьләрне прозага чәчмә формага әйләндерү, оригинал белән чагыштырып чыгаруга өйрәтү. Эпитет, гипербола, метонимия, метафора, сынландыру кебек сурәтләү чараларыннаң әһәмиятен ассоциатив формаларда әдәби әсәрләрдә кулланышын аңлау һәм кулланырга өйрәтү. Тәрҗемә эше белән шөгыльләнү, иҗади күнегүләр башкару.
*Җиһазлау.* Ш. Галиев, Р. Миңнулин, Р. Вәлиева, И.Юзиевның шигырь җыентыклары.

**7 тема. Тел – матурлык ачкычы.** Сөйләм культурасы. Әдәби телдә грамматик, морфологик нормалар. Язма һәи сөйләм телендә стильләр. Татар дикторлары Эльмира Хамматова, Инсаф Абдулла, Резедә Гәрәева. ***Сөйләм культурасы өстендә эш.***

Шигърият баскычлары. Т. Галиуллин, Юзеев, Р.Харис, Ф.Мөхәммәтова, К.Булатова иҗаты. Авторлар иҗатыннан үрнәкләр. Шигырьләрдәге тел – сурәтләү чаралары, ритмик яңгырашы, эпитетлар, чагыштырулар сынладырулар, метафоралар. Шәһәребездә яшәп иҗат итүче шагыйрьләр һәм язучылар

*Җиһазлау.* Людмила Аланлы, Әлфия Сибгатуллина, Ралия Кәримованың җыентыклары, альбомнар. Шагыйрьләрнең эшчәнлегенә кагылышлы мәкаләләр, альбомнар, карточкалар, аудиокассеталар. "Телләр белгән – илләр гизгән", "Тел – тарих көзгесе", " Тел – ил сагында" китаплары, журналлар, аудио – видео язмалар.

**8 тема. Халкыбызның күңел бизәкләре – кул эшләре.** Музейлар эшчәнлеге. Экспонатлар ни сөйли? ***Өйрәнелгән материал буенча телдән сораштыру***

*Җиһазлау.* Альбомнар, картиналар. Дөнья музейлары альбомнары видеокассеталар, аларга кагылышлы мәкаләләр, кул эшләре үрнәкләре (чигешләр, шәлъяулыклар, чокып һәм тукып ясалган эшләр.

**9 тема Түбән Кама- туган төбәгем**

*Максат.* Үзебезнең туган төбәгебезнең истәлекле урыннарын белү максатыннан фотога төшереп алып, шулар турында сөйләү. Төрле чыганаклар аша туган як тарихын өйрәнү, материаллар туплау, истәлекле тарихи урыннарны өйрәнү. ***"Түбән Кама- туган төбәгем" темасына күргәзмә эшләү.***

*Җиһазлау*. Рәфәт Шәйдуллин. Мәсәлләрем-дусларым. - Казан: "Ихлас" нәшрияты. - 2010.- 287б.,Фәтхулла Абдуллин.Тормышка юл ярганда...:повестьлар һәм хикәяләр - Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2012. -272 б.,Фәтхулла Абдуллин. Җан җылысы. Очерклар, хикәяләр, публицистика. –Казан: "Идел-Пресс" нәшрияты, 2012.-176 б.

**10 тема. Гаилә тарихы-халкыбыз тарихы**

*Максат*. Укучылар үзләренең шәҗәрә агачы, исемнәренең килеп чыгышы, мәгънәсе турында кыска күләмле эзләнү- тикшеренү эшчәнлеге алып баралар. ***Кыска күләмле фәнни- тикшеренү эшләре башкару.***

*Җиһазлау*. Темага кагылышлы альбомнар, аудио – видеокассеталар, мәкаләләр, ноутбук, интерактив такта, видеомагнитофон.

**11 тема: йомгаклау дәресе.**

Максат: түгәрәк эшчәнлегенең еллык эшенә нәтиҗә ясау.

Еллык эшебезгә нәтиҗә ясау. Нинди уңышларга ирештек. Фикерләр алышу. Алдагы уку елына планнар. Үткәннәрне кабатлау. ***Тест биремнәре башкару.***

## 3 ЕЛ УКЫТУГА УКУ ПЛАНЫ

| № | Тема | Барлык сәгать | Теория | Практика | Аттестация формалары |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Кереш дәрес | 3 | 3 | - | Аралашу, тест сораулары |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 2 | Татар теленең үсеш баскычлары. | 6 | 3 | 3 | аралашу |
| 3 | Р. Фәхреддиннең педагогик эшчәнлеге | 45 | 20 | 25 | Үзлектән эш |
| 4. | “Исемең матур. Кемнәр куйган?” | 45 | 15 | 30 | Зачет эше |
| 5. | Җан дәвасы - шигъриятә | 28 | 10 | 18 | Иҗади бәйге |
| 6. | Театр яктылыкка, нурга илтә. | 43 | 18 | 25 | Эшлекле уен |
| 7. | Халык әйтсә – хак әйтә. Татар халык иҗаты.Балалар фольклоры | 16 | 10 | 6 | Тест сораулары |
| 8. | Түбән Каманың күренекле шәхесләре. | 30 | 10 | 20 | Иҗади бәйге |
| 9. | Йомгаклау | 2 | 2 | | Реферат яклау |
| | Барлык сәгать: | 216 | 89 | 127 | |

## 3 ЕЛ УКЫТУГА ПРОГРАММА ЭЧТӘЛЕГЕ

**1 тема. Кереш дәрес.** Куркынычсызлык техникасы кагыйдәләре. Берләшмәнең планы белән танышу. Юл йөрү кагыйдәләре буенча әңгәмә.***Тест биремнәре башкару***

*Күрсәтмә материал*: Обучение школьников правилам безопасного поведения на дороге (5-9 классы): Учебно-методическое пособие / Р.Ш.Ахмадиева, С.А.Бикчентаева, Д.Д.Забиров, Е.Е.Воронина и др./ Под общей ред. Р.Н.Минниханова, Д.М.Мустафина. – Казань: ГБУ «НЦ БЖД», 2013 г

**2 тема. Татар теленең үсеш баскычлары**.

*Максат.* Татар теленең килеп чыгышы, үсеш тарихы турында мәгълүмат бирү. ***Өйрәнелгән материал буенча телдән сораштыру***

*Җиһазлау*. Гомуми мәгълүмат, күнегүләр, коммуникатив биремнәр, контроль тестлар Э.Н.Денмөхәммәтова, Г.Р. Мөгътәсимова, Ә.Ш.Юсупова, Г.Ә.Нәбиуллина, Казан — 2009. ”Әдәбият һәм сәнгать чынбарлыгы”, “Татары – этнос или этноним” китаплары. Газета материаллары, альбомнар.

**3 тема. Р. Фәхреддиннең педагогик эшчәнлеге**

*Максат*. Р. Фәхреддиннең педагогик эшчәнлеге белән якыннан танышу.

***Өйрәнелгән материал буенча телдән сораштыру***

*Җиһазлау.* Мәшһүр мәгърифәтче – галим, педагог Ризаэддин Фәхреддин мирасын укыту – тәрбия процессында файдалану. 2 кисәк, Казан, 2006, Ризаэддин бине Фәхреддин: Тормыш юлы, иҗади мирасы. Дәреслек- хрестоматия/ Төз.-мөх. Р. Шаһиев.- Казан: РИЦ “Школа”, 2005.-272 б ., Ризаэддин бине Фәхреддин. Балаларга үгет-нәсыйхәт. – Казан. “Дом печати” нәшрияты. 2001, Ризаэддин бине Фәхреддин. Фәнни – биографик җыентык. Казан: “Рухият” нәшрияты. 1999, журналлар, аудио – видео кассеталар, ноутбук.

**4 тема. “Исемең матур. Кемнәр куйган?”**
*Максат*. Гаилә әгъзаларының, сыйныфташларның исемнәре турында мәгълүматлар туплау. Кешенең исеме тормышына һәм язмышына йогынты ясавы турында аңлату.***Укучылар гаилә әгъзаларының, сыйныфташларның исемнәре турында мәгълүматлар туплыйлар һәм шулар хакында сөйлиләр.***
*Җиһазлау.* Гомәр Саттар-Мулилле “Татар исемнәре ни сөйли?” Казан, “Раннур” нәшрияты,1998 ел.,Ф.
**5 тема. Җан дәвасы - шигърияттә**
Максат.Татар шигъриятенең үзенчәлекләре. Шигырь төзелеше. Ритмик яңгыраш. Озын, кыска үлчәмдәге шигырьләр. Укучыларны сәнгатьле шигырь сөйләү бәйгеләрендә катнашырга этәрү. ***Сәнгатьле шигырь сөйләү бәйгеләрендә катнашу.***
Җиһазлау. «Мирас”, “Казан”, «Мәгариф» журналлары, альбомнар, аудио – видеокассеталар, шагыйрьлрнең җыентыклары, ноутбук, интерактив такта, видеомагнитофон.
**6 тема. Театр яктылыкка, нурга илтә...**
Максат. Театр сәнгате, татар театрлары турында мәгълүмат бирү. ***Спектальләр карау.***
Җиһазлау. Арсланов М.Г.Татар театры : Энциклопедик сүзлек – белешмә. – Казан: “Заман” нәшр., 2014. – 455,492 б., Гыйззәт Т. Истәлекләр, мәкаләләр / авт. – төз. К. Гыйззәтов. –Казан : Тат.кит. нәш. , 2010. – 19-20 б., И. Илялова Камал театры артистлары. -Казан: ТКН., 1999. - 18б., Россиядә – Театр елы // Сәхнә. 2019. -№ 1. – 2б.
**7 тема. Халык әйтсә - хак әйтә. Татар халык иҗаты.** Мәкаль – әйтемнәр, ышанулар, юраулар. Әкиятләр. Балалар фольклоры уен – йола җырлары, такмаклар, такмазалар, туган ил турында җырлар, лирик җырлар. Җырларның теле. ***Туган төбәгеңнең халык авыз иҗатын туплау.***
*Җиһазлау.* Татар халык иҗаты 1 – 5 томнар, җыр җыентыклары, аудиокассеталар
**8 тема. Түбән Каманың күренекле шәхесләре.**
Максат. Укучыларны Түбән Каманың күренекле шәхесләре: әдипләре, язучылары, җырчылары , композиторлары, шәһәребезгә нигез салган кешеләре белән таныштыру. ***“Түбән Каманың күренекле шәхесләре” темасына күргәзмә эшләү.***
*Җиһазлау.* Альбомнар, видеокассеталар, китаплар, буклетлар.
**9 тема: Йомгаклау дәресе.**
Максат: түгәрәк эшчәнлегенең еллык эшенә нәтиҗә ясау.
Проект яклау. Үткәннәрне кабатлау. Түгәрәк эшчәнлегенең еллык эшенә нәтиҗә ясау.

Йомгаклау чыгышы. Йомгаклау аттестациясен уңышлы үткән чыгарылыш укучыларына "Тел күрке- сүз" өстәмә гомуми белем бирү программасын үзләштерү хакында таныклык бирелә.

## ПРОГРАММАНЫҢ ПЕДАГОГИК-ОЕШТЫРУ ШАРТЛАРЫН ТОРМЫШКА АШЫРУ

**Материаль-техник база:**
1. *Дәресләр балалар берләшмәсе өчен туры килә торган, җылы, иркен, теоретик һәм практик дәресләр үткәрү өчен җайланылган.*
2. *Җиһазлар:*
Укучы урындыгы – 20 шт.;
Укучы өстәле – 10 шт.;
Укытучы өстәле – 1 шт.;
Укытучы урындыгы – 1 шт.
*3. ТСО чаралары*
-- ноутбук – 1 шт.
- колонка – 2 шт.
- проектор белән экран
4. *Материаллар һәм җиһазлар*:
- тарату материаллары( схемалар)
-информацион материаллар,
- карточкалар,
- дәресләр өчен кирәкле рәсемнәр,
- методик эшләнмәләр, тестлар, система һәм гомумиләштерүче таблицалар.
- укытучы ноутбугы.

**Программаның укыту-методик яктан тәэмин ителеше**
*1Методик комплекслар:*
- информацион материаллар;
- карточкалар;
- дәресләр өчен кирәкле рәсемнәр;
- методик эшләнмәләр.

2. *Дидактик материаллар* (демонстратив һәм тарату) - журналлар, буклетлар, альбомнар, карточкалар.
Программа төрле төрдәге бәйге, ярышлар өчен оптималь мөмкинлекләр булдыру, укучыларның иҗади эшләре өчен җирлек тудыруны күздә тота.
*Укыту бурычларының чишелешенә карап дәресләр түбәндәге төрләргә бүленә*:
- *иҗади эшләрне яклау*;
- *эзләнү*- тикшеренү дәресе;
- *дәрес*- практикум;
- *дәрес*- диолог;
- белемнәрне ныгыту дәрес;
- яңа белемнәрне бирү дәресе;
- белемнәрне тикшерү дәресе.

*Программаның гамәлгә ашыруылы өчен кирәкле шартлар:* уку процессының максатчанлыгы; укучыларның дәресләргә системалы рәвештә йөрүе; табигый сәләтне этаплап үстерү; уку материаланың аңлаешлы булуы; балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алу; һәрбер балага индивидуаль якын килү; дәресләрдә уңай психологик халәт тудыру.

Программаның үтәлешен билгеләү һәм тикшерү өчен: тестлар, контроль эш өчен күнегүләр, система һәм гомумиләштерүче таблицалар.

Программа төрле төрдәге бәйге, ярышлар өчен оптималь мөмкинлекләр булдыру, укучыларның иҗади эшләре өчен җирлек тудыруны күздә тота.

*Диагностика үткәрү материаллары*: тестлар, дидактик уеннар, кроссвордлар.
Укыту практикасында видеотека материаллары кулланыла, болар төрле бәйгеләр (муниципаль, төбәкара, республикакүләм) вакытында төшерелгән чыгышлар. Бу материаллар "Тел күрке - сүз" берләшмәсенә йөргән укучыларның ирешкән уңышларына нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә.

***Программаны методик тәэмин итү***

Шәхескә юнәлтелгән технологияләр:

- -Ш.А.Амонашвилиның шәхескә хөрмәт белән карау технологиясе;
- үзара хезмәттәшлек педагогикасы технологиясе.
- Укучылар эшчәнлеген активлаштыру һәм интенсивлаштыруга нигезләнгән педагогик технологияләр:
- уен технологисе;
- проблемалы укыту;
- аралашуга өйрәтү технологиясе.

Уку процессын оештыру һәм идарә итүнең нәтиҗәлелегенә нигезләнгән педагогик технологияләр:

- терәк схемаларны кулланып, алга китеп укыту технологиясе;
- белем бирүнең компьютер технологияләре;
- интенсив белем бирү технологиясе
- электрон дәреслекләр һәм ярдәмлекләр.

Яңа мәгълүмати технологияләр проект эшчәнлеген киң җәелдерергә дә мөмкинлек бирә. Дәресләрдә эшләнергә мөмкин булган кечкенә проектлар да, презентация ясау белән төгәлләнүче зурлары да компьютер технологиясен куллануны күздә тота.

Проект эшчәнлегендә компьютер куллану нәтиҗәсендә: үзлектән белем алуга омтылыш арта, креативлык, шәхеснең үзбәясе үсә, уку процессында таләп ителмәгән шәхси сыйфатлар ачыклана һәм үсә (иҗади эшкә осталык, музыка, рәсем сәнгате өлкәсендәге сәләт), яңа күнекмәләр булдырыла (мәгълүмат җыю, эшкәртү, компьютер презентациясе формасында тәкъдим итү, фикерләрен дәлилләү

Программа балаларны укыту, иҗади яктан үстерү, тәрбия бирү аспектларының бердәмлегенә нигезләнгән.

*Программаны тормышка ашыруның төп принциплары:*

- баларның яшь үзенчәлекләре исәпкә алынган;
- аңлылык принципы балаларның кызыксыну, аңлап эш итә белү дәрәҗәләре.

*Бәяләү материаллары*

–бәйгеләрдә катнашу, проектлар яклау, тестлар, биремнәр эшләү программаны

тиешле югарылыкта үзләштерүдә ярдәм итә.

Программа педагог белән берлектә төп күнекмәләрне һәм гамәли эшләрне, техника куркынычсызлыгы кагыйдәләрен белүне күздә тота. Дәресләр балалар берләшмәсе өчен туры килә торган теоретик һәм практик дәресләр үткәрү өчен җайланылган.

**Аттестация формалары/контроль һәм бәяләү материаллары**

*Аттестация / контроль формалары*

Укучыларның программа материалын үзләштерү киләсе контрольне үткәрү барышында күзәтелә:

- *Кереш контроль*. Ул һәр уку елы башында, белем бирү процессы башланганчы укучының белем дәрәҗәсен бәяләү өчен үткәрелә. Ул рәвешендә уза.
- *Агымдагы контроль.* Программаны гамәлгә ашыруның бөтен срогы дәвамында (зур бүлекне өйрәнү тәмамланганнан соң, ярты еллыкта) үткәрелә . Ул тест һәм шигырь бәйгесе рәвешендә узарга мөмкин.
- *Арадаш аттестация.* Программаны үзләштерү тәмамланганнан соң ,программаны тормышка ашыруга йомгак ясау, программаны үзләштерү нәтиҗәлелеген билгеләү өчен үткәрелә. Арадаш аттестация укуның беренче, икенче елы ахырында тест һәм текст өстендә эш формаларында уздырыла
- *Йомгаклау контроле.* Программаны үзләштерү тәмамланганнан соң проект яклау формасында уздырыла. Программаның үзләштерү нәтиҗәләрен контрольдә тоту һәм күзәтү өчен, һәр бүлектә диагностик инструментарий каралган, бу педагогка уку материалын үзләштерү дәрәҗәсен һәм сыйфатын бәяләргә ярдәм итә.

*Программаны үзләштерү сыйфаты һәм нәтиҗәлеге диагностикасы.*

| ***Үткәрү вакыты*** | ***Үткәрү максаты*** | ***контроль формалары*** |
|---|---|---|
| **1 ЕЛ УКЫТУ** | | |
| ***Кереш контроль*** | | |
| 1 ел укыту башында (сентябрь) | Башлангыч белем дәрәҗәсен билгеләү | Сораштыру тесты |
| ***Агымдагы контроль*** | | |
| 1 ел укыту (декабрь) | укучылар тарафыннан уку материалының үзләштерү дәрәҗәсен бәяләү, планлаштырылган нәтиҗәләргә ирешү сыйфатын билгеләү | Тест |
| ***Арадаш контроль*** | | |
| 1 ел укыту (май) | Укучылар тарафыннан уку материалының үзләштерү дәрәҗәсен билгеләү. Укучыларда укуга карата җаваплылык һәм кызыксыну уяту. | Тест |
| **2 ЕЛ УКЫТУ** | | |
| ***Кереш контроль*** | | |

| | | |
|---|---|---|
| 2 ел укыту башында (сентябрь) | *Балаларның үсеш дәрәҗәсен һәм аларның иҗади сәләтләрен билгеләү.* | *Контроль тест* |
| ***Агымдагы контроль*** | | |
| 2 ел укыту (декабрь) | укучылар тарафыннан уку материалының үзләштерү дәрәҗәсен бәяләү, планлаштырылган нәтиҗәләргә ирешү сыйфатын билгеләү. | *Тестлар* |
| ***Арадаш контроль*** | | |
| 2 ел укыту (май) | укучыларның тәрҗемә итү осталыкларын, сөйләм хаталарын таба һәм сөйләмне дөрес итеп оештыра алуларын тикшерү | ***текст өстендә эш.*** |
| **3 ЕЛ УКЫТУ** | | |
| ***Кереш контроль*** | | |
| 3 ел укыту башында (сентябрь) | укучыларның белем дәрәҗәсен барлау, | Тест |
| ***Агымдагы контроль*** | | |
| 3 ел укыту (декабрь) | уку елы барышында үткән темаларны үзләштерү дәрәҗәсен билгеләү | Шигырь бәйгесе |
| ***Йомгаклау аттестациясе*** | | |
| 3 ел укыту (май) | төрле чыганакларны файдаланып, үзлектән иҗади эш башкара алуын билгеләү | Проект яклау |

*Педагогик мониторинг.*

*Программаны уңышлы үзләштерүнең нәтиҗәләрен системалы күзәтү мониторингы*

| Параметрлар | Критерийлар |
|---|---|
| Белем бирү нәтиҗәләре | Балаларның белем бирү прогаммасының эчтәлеген аңлавы. Белем һәм күнекмәләрнең төрлелеге. Предмет буенча белемнәрнең тирәнлеге.<br>Балаларның практик үсеш һәм иҗади нәтиҗәләре.<br>Иҗат уңышларының төрлелеге (бәйгеләр, конкурслар, фестивальләр, фәнни – гамәли конференцияләр).<br>Игътибарлылык, хәтер, күзаллау кебек гомуми күнекмәләрне формалаштыру һәм үстерү |

| | |
|---|---|
| Тәрбия бирү нәтиҗәләре | Үзеңне культуралы тота белү.<br>Биремнәрне эшләгәндә пөхтә итеп эшләү, эш урынын тәртиптә тотарга тырышу. Башлаган эшне ахырына кадәр җиткерә белү. |
| Социаль - Педагогик нәтиҗәләр | Санитар-гигиена таләпләрен үтәү. Куркынычсызлык, иминлек кагыйдәләрен үтәү. Коллективта аралашу кагыйдәләре.<br>Педагогка мөнәсәбәт. |

Критерийлар күрсәткече түбәндәге дәрәҗәләр белән билгеләнә: югары, уртача, түбән. Мониторинг һәрбер бүлек материалы үтелеп беткәч үткәрелә.

*Белем һәм күнекмәләрнең төрлелеге.*

Югары:
- төрле чыганакларны файдаланып, үзлектән иҗади эш башкара ала;
- халкыбызның гореф – гадәтләрен, традицияләрен аерып күрсәтә ала;
- балалар әдәбиятының матур үрнәкләрен белә;
- сәхнәдә чыгыш ясаудан курыкмый;
- авазлар артикуляциясенең үзенчәлекләрен дөрес тоемлый ;

Уртача:
- сәхнәдә чыгыш ясарга әзер түгел ;
- халкыбызның гореф – гадәтләрен, традицияләрен авыр аера;
- авазларны бик үк дөрес әйтә алмый;
- төрле чыганакларны файдаланып, үзлектән иҗади эшне авыр башкара

Түбән:
- авазлар артикуляциясен тоемлый алмый;
  халкыбызныж гореф - гадәтләрен белми;
- сәхнәдән курка;
- төрле чыганакларны файдаланып, үзлектән иҗади эшне башкара алмый

*Предмет буенча белемнәрнең тирәнлеге.*

Югары:
- татар халкының милләт буларак кайчан оешуын аңлата ала ;
- татар әдәбияты узган тарихи юлны белә;
- татарча аралашу алуы югары

Уртача:
- татар халкының милләт буларак кайчан оешуын җиңел аңлата алмый ;
- татар әдәбияты узган тарихи юлның аерым этапларын гына аңлата ала;
- татарча аралашу алуы уртача
- өстәмә материаллар авыр эшли.

Түбән:
- программа материалын белеп бетерми.
- активлык позициясе, программа үзләштерүдә кызыксынучанлыгы түбән.

Югары:
- эш барышында зур активлык күрсәтә;

- үзлектән эшләргә әзер, өйдә шөгыльләнә;
- башкаларга ярдәм күрсәтә;
- төрле бәйгеләрдә катнашырга ярата.

Уртача

- эш барышында активлык күрсәтә;
- максатка ирешүдә тырыш;
- аерым дәресләрдә актив эшли.

Түбән:

- активлык күрсәтми;
- педагог ныклап таләп ителгән кайбер эшне генә эшли.

*Иҗат уңышларының төрлелеге.*

Югары: һәрдаим төрле дәрәҗәдәге бәйгеләрдә катнаша.

Уртача: мәктәпкүләм һәм "Тел- күрке сүз" берләшмәсе кысаларында узган бәйгеләрдә катнаша.

Түбән: "Тел- күрке сүз" берләшмәсе кысаларында узган бәйгеләрдә бик сирәк катнаша.

*Танып белү күнекмәләрен үстерү.*

Югары: иҗади фикерләү сәләте көчле, куелган сорауларга төгәл җавап бирә, игътибарлы.

Уртача: сорауларга җавапны белсә дә, фикерләрен матур итеп әйтеп бирә белми, игътибары җитеп бетми.

Түбән: дөрес фикерли белми, игътибарсыз.

*Тәрбияви компонентларның мониторингы.*

*Баланың үз – үзен тоту культурасы.*

Югары: әхлак турында үзенең тирән фикерләре бар, тәртип нормаларын саклый, әхлак сыйфатларын (игелеклелек, хөрмәт итү, дисциплина).

Уртача: әхлак кагыйдәләре турында фикер йөртә, тәртип нормлараын гел саклый алмый.

Түбән: әхлак кагыйдәләрен бөтенләй белми, тәртип нормаларын сакламый диярлек.

*Коллективта мөнәсәбәтләр характеры*

Югары: югары коммуникатив культура, коллектив эшләрендә актив катнаша.

Уртача: коммуникатив сыйфатлар бар, ләкин коллектив эшендә катнашырга ояла.

Түбән: коммуникатив сыйфатлар түбән, коллективта аралашу теләге юк.

*Социаль-педагогик мониторинг нәтиҗәләре.*

*Санитар - гигиеник таләпләрне үтәү .*

Югары: эш барышында пөхтә, эш беткәч кулларын юа.

Уртача: санитар-гигиеник таләпләрне укытучы әйткәч кенә эшли.

Түбән: санитар – гигиеник таләпләрне үтәүдән баш тарта.

*Куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәү.*

Югары: барлык куркынычсызлык кагыйдәләрен дә үти.

Уртача: куркынычсызлык кагыйдәләрен укытучы кушкач кына үти .

Түбән: таләпләрне үтәми, сорауларга теләми җавап бирә, биремнәрне кызыксынып эшләми.

*Программаны үзләштерү критерийлары.*

Программаны үзләштерү критериялары булып балаларның беренче елдан өченче елга кадәр үсешләре, материалны программа буенча үзләштерүләре, зур сәхнәдә тамашачы алдында махсус номерлар белән чыгыш ясауы тора.

Программаны үзләштерү өч дәрәҗәдә бәяләнә:

“Югары дәрәҗә” – уку программасын 70% - 100% кадәр үзләштерү, балалар тулысынча көтелгән нәтиҗәләргә ирешеп программаны үзләштереп чыгалар.

“Уртача дәрәҗә” - уку программасын 40% - 70% кадәр үзләштерү, балалар өлешчә көтелгән нәтиҗәләргә ирешеп программаны өлешчә үзләштереп чыгалар.

“Түбән дәрәҗә” - уку программасын 40% тан түбән үзләштерү, балалар программаны авыр үзләштереп чыгалар.

Өч ел берләшмәгә йөреп Бөтенрәсәй , республика, район һәм шәһәр күләмендә үткәрелгән бәйгеләрдә призлы урыннар алган балалар программаны тулысынча үзләштергән дип исәпләнә.

Программа милли-төбәк компонентын исәпкә алып, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауны күздә тотып төзелде. Шулай ук программага 6 сәгатькә исәпләнгән “Юл куркынычсызлыгы” буенча тематик укыту модуле кертелде.

*Нәтиҗәләр чыгаруның төп формалары*

3 елга исәпләнгән бу программаны тормышка ашыруны ачык дәресләр, тестлар, биремнәр, күп төрле концерт программаларында, бәйгеләрдә, фестивальләрдә чыгышлар тәшкил итә.

БЕЛЕМ ДӘРӘҖӘСЕН ТИКШЕРҮ МАТЕРИАЛЛАРЫ

**1нче ел укыту**
**Кереш контроль**

**Максат:** укучыларның башлангыч белем дәрәҗәсен билгеләү
**Контроль формасы:** тест- сораштыру

**Сораштыру**

**1. Син Түбән Кама шәһәрендә Балалар һәм яшьләр иҗаты сарае барлыгын белә идеңме?**
а) юк;
б) ишеткән идем;
в) анда булганым да бар иде

**2. “Тел күрке- сүз” берләшмәсенә ничек килергә уйладың?**
а) үз теләгем белән;
б) дустым чакырды;
3) әнием киңәше белән

**3. “Тел күрке- сүз” берләшмәсенә нинди максатат белән килдең?**
а) матур сөйләшергә өйрәнү өчен, әдәби әсәрләр турында күбрәк белү өчен;
б кызык өчен;
в) дустым йөргәнгә күрә

**4. Берләшмәдә алынган белем- күнекмәләр сиңа киләчәктә кирәк булыр дип уйлыйсыңмы һәм ни өчен?**
а) туган телдә матур сөйләшә белүче кешегә тормышта үз урынын табу да җиңелрәк булачак;
б) сәнгать дөньясы кануннары белән яшәгән кеше җәмгыятьтә зур проблемаларны чишәргә сәләтле булып, һәрьяктан камил шәхес буларак формалашачак;
в) үз балаларын туган телдә сөйләшергә өйрәтә, милли тәрбия бирә алачак

**5. Сине нинди әдәби әсәрләр күбрәк кызыксындыра?**
а) шигырьләр;
б) әкиятләр;
в) пьесалар

**6. Син сәхнәдә нинди хис- тойгыны белдергән шигырь сөйләр идең?**
а) шаян, көлкеле, шук;
б) моңсу, сагышлы;
в) батырлык, кыюлык

**7. Сиңа иптәшләрең белән аралашу авырлык тудырамы?**
а) юк;
б) аралашу серләренә өйрәнергә тырышам;
в) миңа яңа кешеләр белән аралашу зур кыенлык тудыра

**8. “Тел күрке- сүз” берләшмәсе бу юнәлештә сиңа булышыр дип уйлыйсыңмы?**
а) юк;
б) күпмедер дәрәҗәдә;
в) тулысынча

**Бәяләү критерийлары:**

| Дәрәҗә | балл |
|---|---|
| Югары | 8 балл |
| Уртача | 7- 5 |
| Түбән | 4 әзрәк |

**Агымдагы конторль**

**Максат:** тел гыйлеме,  халык авыз иҗаты әсәрләре үрнәкләрен  белү буенча әзерлек сыйфатын, балалар язучылары, аларның әсәрләрен белү күнекмәләрен бәяләү, планлаштырылган нәтиҗәләргә ирешү дәрәҗәсен билгеләү
**Контроль формасы:**  тест

**Тест**

1.**Кайсы рәттәге сүзләрнең язылышлары дөрес?**
а) мәнге, борыңгы, алдыңгы;
ә) мәңге, борынгы, алдынгы.

2. **«Үги кыз» әкиятендә кайсы мәкаль очрамый?**
а)Тырышкан табар, ташка кадак кагар.
ә)Кыңгырэш кырык елдан соң да беленә.
б)Ни чәчсәң, шуны урырсың.

3**. А. Алиш әсәрләре арасыннан әкият жанрында язылганнарын дөрес билгелә.**
а) "Нечкәбил";
ә) "Сертотмас үрдәк";
б) "Якты күл буе";
в) "Ялкаулык-хурлык, тырышлык-зурлык";
г) "Дулкыннар".

4.**Тартык авазлар яңгырау һәм саңгырау дигән төрләргә ничек бүленәләр?**
а) авазларның әйтелешләре ягыннан үзара җайлашуыннан чыгып;
ә) әйткәндә тавыш һәм шауның катнашуыннан чыгып;
б) тартыклар үзара тәэсир итешеп, ике охшаш булмаган аваздан
бертөрле яки охшаш авазлар формалашудан чыгып.
5. **Әйтелешендә сузыклар гармониясе сакланган сүзләрне тап.**
а) хәйран, фаҗигале;
ә) фикердәш, төпчек;
б) гомер, табигать

6.**Дөрес язылышлы сүзләрне тап.**
а) умбиш, төмбоек, алдыңгы;
ә) клуп, флак, состаф;
б) төнбоек, флаг, унбиш.

7.**Кайсы рәттә бары тик Г.Тукайның әсәрләре генә урнашкан?**
а) “Бала белән күбәләк”, “Гали белән Кәҗә”, “Шүрәле “;
в) “Су анасы”, “Каргалар оясы”, “Җиңү бәйрәме”;
с) “Сарык белән кәҗә”, “ Сертотмас үрдәк, “Дәү әнием”

8. **«Олыласаң олыны, олыларлар үзеңне» мәкале кайсы әкияткә туры килә?**
а) «Су анасы»;

б) «Тату туганнар»;
в) «Чукмар белән Тукмар»

**Җаваплар:**
1 2 3 4 5 6 7 8
ә б (а,ә,в) ә ә б а б

**Бәяләү критерийлары:**

| **Дәрәҗә** | **балл** |
|---|---|
| Югары | 8 балл |
| Уртача | 7- 5 |
| Түбән | 4 әзрәк |

**Арадаш конторль**

**Максат:** укучыларның тарихи үткән юлыбызны, татар балалар язучыларын, халык иҗаты әсәрләрен тануларын, аралашу, эш кәгазьләрен, дөрес язу күнекмәләрен бәяләү, планлаштырылган нәтиҗәләргә ирешү дәрәҗәсен билгеләү

**Контроль формасы:** тест

**Тест**

1. **Җансыз предметны, күренешне җанлы итеп күрсәтү.**
а) сынландыру;
б) чагыштыру;
в) рифма

2.**Р.Миңнуллин кайсы китабы өчен Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе белән бүләкләнә?**
а)"Күчтәнәч"
б)"Безнең авыл зоопаркы"
в)"Энекәш кирәк миңа"
г)"Дөньядагы иң зур алма"

3. **Эш кәгазе булмаган рәтне сайлап ал**
а) Хат. Эш хатлары. Рәсми хатлар. Котлау хатлары. Шәхси хатлар
б) Сыйфатнамә (Характеристика)
в) шигырь, поэма

**4. “Без капчыкта... мәкальнең дәвамын тап**
а) ятмый;
б) кадак кагар;
в) тырышлык кирәк

5. **“Каз канаты “ җыры**

а) уен – йола җыры;
в) озын көй;
с) лирик җыр

6. **“Милли моңнар ” шигыренең авторы кем?**
а) Һади Такташ;
б) Хәсән Туфан;
в) Габдулла Тукай;
г) Муса Җәлил.

7.**Халык авыз иҗатына керми:**
а) әкиятләр
ә) мифлар
б) мәсәлләр
в) халык җырлар

8. **Әлеге сүзләрне тиешле тәртиптә урнаштырып, тыныш билгеләрен куеп, шигырь юллары языгыз.**
Нурыннан, иртәнге,таң, Ромашкалар, уянды, Сорашып, хәл, елмаеп, Караштылар, күзгә - күз.
- Әлеге юлларның авторы кем?
- Өзек кайсы әсәрдән алынган?

9. **Бирелгән сүзләрдән җөмләләр төзеп яз.**
1. Яшьтәшләр, очрашырга , без, еш ,белән, яратабыз.
2. Һәрвакыт, тиеш, өлкәннәрне,  хөрмәт итәргә, кечкенәләр.
3. Тырыш, минем, әтием, кеше.
4. Өлкән, автобуста, урын,бирергә, кешеләргә, кирәк

10.**Түбәндәге сүзләрнең антонимнарын табып яз.**
бай- ... салкын- ...
зур- ... биек -...
калын- ... усал- ...
күп- ... кыш- ..

**Җаваплар**
1 2 3 4 5 6 7 8 9 10

а а в а а в б М. Җәлил ( дөрес җавапларга 1 балл)

**Бәяләү критерийлары:**

| Дәрәҗә | балл |
|---|---|
| Югары | 10 |
| Уртача | 9 - 5 |
| Түбән | 4 әзрәк |

**2 ел укыту**

Кереш конторль

**Максат:** укучыларның халык иҗаты әсәрләрен тану күнекмәләренең камилләшүен, җөмһүриятебез, шәһәребез турында белемнәрен барлау

**Контроль формасы:** тест

**Тест.**

**1. 30нчы август нинди көн?**

а) Сабантуй

б)Җиңү көне

в)Республика көне

г)Яңа ел

**2.Халык авыз иҗаты әсәрләре булган рәтне тап.**

а) әйтем, мәкаль, табышмак;

б) Шәүкәт Галиев “Кошлар китә”, М.Гафури “Ана теле”;

в) Р. Әхмәтҗанов “Туган телем”, Н.Нәҗми “Татар теле”

**3. Зиһен сынаш уеннары**

а) “Ватык телефон” “Май чүлмәге,” “Кап та коп”;

б) “Сукыр тәкә”, “Кәбестә”, “Буяу сатыш”;

в) «Кәрия – Зәкәрия”, “Ак калач”, “Йөзек салыш”

**4.Татарстанда нинди телләр дәүләт телләре?**

а) татар

б) рус

в) татар, рус

г) татар, рус, инглиз

**5. “ Күбәләгем” җыры**

а) уен – йола җыры;

б) такмак;

в) озын көй

**6. “Егет кешегә җитмеш төрле... мәкальнең дәвамын тап**

а) һөнәр дә аз;

б) кадак кагар;

в) тырышлык кирәк

**7.Түбән Кама шәһәренә кайчан нигез салынган?**

а) 1930 нчы ел, 30 нчы август;

б) 1972 нче ел, 4 нче декабрь;

в) 1965 нче ел, 15 нче май.

**8. “Әбүгалисина” әсәрен кем язган?**

а) Каюм Насыйри;

б) Габдулла Тукай;

в) Җәвад Тәрҗеманов

**9. Мәгънә ягыннан охшаш сүзләр ничек атала?**
а) антонимнар;
б) чагыштырулар;
в) синонимнар
**10. Хезмәт белән бәйле йолалар:**
а) өмәләр
ә) Нардуган
б) боз озату
**Җаваплар**
1) в, 2)а, 3) б, 4) в, 5) а , 6) а, 7) в, 8)а, 9 ) в, 10) а
**Бәяләү критерийлары:**

| **Дәрәҗә** | **балл** |
|---|---|
| Югары | 10 |
| Уртача | 9 - 5 |
| Түбән | 4 эзерәк |

**Агымдагы конторль**
**Максат: укучылар тарафыннан уку материалының үзләштерү дәрәҗәсен бәяләү, планлаштырылган нәтиҗәләргә ирешү сыйфатын билгеләү.**
**Контроль формасы:** тест
**Тест**

**1.Кем ул Николай Васильевич Лимаев?**
а) укытучы;
б) күренекле табиб;
в) Түбән Кама Нефтихим берләшмәсенең беренче генераль директоры
**2.Татарстан флагы түбәндәге төсләрдән тора**
а) яшел, зәңгәр, кызыл;
б) яшел, ак, кызыл;
в) зәңгәр, ак, кызыл,
3. **Шәһәр музее кайсы урамда урнашкан?**
а) Төзүчеләр урамы;
б) Шинчылар урамы;
в) Кайманов урамы.
**4.Халык авыз иҗаты әсәрләре булган рәтне тап.**
а) тизәйткеч, үртәвеч, табышмак;
б) Г.Тукай “ Кызыклы шәкерт”, Х.Туфан “Туган тел””;
в) Р.Миңнуллин “Малайлар бәйрәме иде”, Ш.Галиев “Гыйльман – Вилдан”
**5. Бәби тугач,аны кая алып барганнар?**
а) уенчыклар кибетенә;
б) мунчага;
в) туганнарына
**6. Түбән Кама музыка училищесы кем исемен йөртә?**
а) Сара Садыйкова;

б) Салих Сәйдәшев;
в) Мирсәет Яруллин

**7. “Иренгән ... мәкальнең  дәвамын тап**

а)  ике эшләр;
б)  кадак кагар;
в)  тырышлык кирәк

**8. Татар теленең “Фразеологизмнар сүзлеге” н кем төзегән?**

а) Г.Тукай
б) Н.Исәнбәт
в) Ф.Әмирхан

**9.“Бер дидем – бер мәк, ике дидем – икмәк,**
**Өч дидем – өчмәк, дүрт дидем – дүрт мәк, биш дидем – бишмәт”**

а) тизәйткеч;
б) табышмак;
в) санамыш

**10. Хатын – кызларның милли бизәнү әйбере:**

а) кершән;
б) чулпы;
в) балдак

**Җаваплар**

1  2 3 4  5  6  7 8 9 10
в   а а а  б  а  а  б  а   б

**Бәяләү критерийлары:**

| **Дәрәҗә** | **балл** |
|---|---|
| Югары | 10 |
| Уртача | 9 - 5 |
| Түбән | 4 әзрәк |

## Арадаш  конторль

**Максат:** укучыларның тәрҗемә итү осталыкларын, сөйләм хаталарын таба һәм сөйләмне дөрес итеп оештыра алуларын тикшерү.

**Контроль формасы:**  текст өстендә эш.

### Текст өстендә эш

**1.** Тәрҗемәи диктант. ***Укучылар тәкъдим ителгән сүзләрнең татарча вариантларын язалар:***

Традиция, повар, результат, километр, семья, адвокат, судья, пожар, группа, духи, продукт, кресло, ящик, конфликт, стена, биография, политика, культура, экономика, больница, поликлиника, санаторий, аптека

**2. Сөйләм хаталарын табыгыз һәм төзәтегез.**

Район киңәшмәсендә.

Вакыт кич. Әкрен генә ябалак кар ява. Район главасы колхоз председательләрен киңәшмәгә җыйды. Алар бүгенгесе көнне әһәмиятле булган мәсьәләләрне хәл итәргә җыеналар.

Беренче булып “ Шахтер “ колхозыннан килгән Г.Мәрдәновка сүз бирелде:
Безнең сөт сату буенча показательләребез начар түгел дип әйтәсем килә. Барлык крупный рогатый скот прогулкага чыга, ашатырга җитә. Көненә 2.5 тонна сөт реализовать итеп барабыз. Дояркалар да тырышып эшли. Эшләгәненә карап зарплата да яхшы гына чыга. Ә менә производство мясада эшлисе эшләр эшләнмәгән әле, резервлар җитәрлек.

“Күңгәр“ колхозы рәисе агымдагы ремонт эшләре турында информация бирде:

-Тракторларны, сеялка һәм башка тагылма коралларны үзебез дә ремонтлыйбыз. Мастерскойлар җылы, запчасть белән дә өзеклек булганы юк.

**3. Түбәндәге җөмләләрне логик эзлеклелек сакланырлык итеп, тиешле тәртиптә урнаштырыгыз.**

Түбән Тагил педагогия институтының сәнгать-графика факультетында укый. 1969 елда Татарстанга кайта һәм 30 елдан артык биредә, Түбән Кама шәһәрендә яши һәм иҗат итә. Авыл мәктәбен тәмамлаганнан соң, ул Самара өлкәсенең Камышлы татар педучилищесында белем ала. Танылган татар рәссамы, сынчы, Татарстанның халык рәссаме, Русия Рәссамнар берлеге әгъзасы Әхсән Сарыйм улы Фәтхетдинов 1939 елның 7 июнендә Чирмешән районы Үтәмеш авылында туа. Аннан соң берникадәр вакыт укытучы булып эшли.

3.а). Текстны укыгыз, эчтәлеге буенча биш сорау төзегез һәм төркемдәшләрегез белән әңгәмә корырга әзерләнегез.

3.б.) Агачтан уеп декоратив-нәкыш ясаучылар һәм монументаль рәсемнәр иҗат итүчеләрдән тагын кемнәрне беләсез? Берсе турында тулырак мәгълүмат табып, текстны тулыландырыгыз.

**Тест.**

1. Ә. Фәтхетдинов Түбән Кама педагогия институтының сәнгать-графика факультетында укый. Дөрес/Дөрес түгел.
2. Ә. Фәтхетдинов иҗатының башлангыч этабы агачтан уеп декоратив-нәкыш ясауга багышланган. Дөрес/Дөрес түгел.
3. Ә. Фәтхетдиновның скульптур композицияләрендә шагыйрь М. Җәлил һәм җәлилчеләр урын алган. Дөрес/Дөрес түгел.
4. Ә. Фәтхетдинов күп кенә объектларны, җәмәгать биналарын бизәкләп эшләүдә катнаша. Дөрес/Дөрес түгел.
5. Ә. Фәтхетдинов утыз елдан артык Самара өлкәсендә яши һәм иҗат итә. Дөрес/Дөрес түгел.

Бәяләү критерийлары:

| Дәрәҗә | Хата саны | балл |
|---|---|---|
| Югары | Хатасыз яки бер хаталы эшкә | 10 |
| Уртача | 2-3 хасы булган эшкә | 9 - 5 |
| Түбән | 4-5 хатасы булган эшкә | 4 әзрәк |

**3 ел укыту**

**Кереш конторль**

**Максат:** укучыларның халык иҗаты әсәрләрен тану күнекмәләренең камилләшүен, халкыбызның йолаларын, кул эшләрен белүләрен барлау.

**Контроль формасы: тест**

**Тест**

**1. Татрстанның иң зур елгасы нинди?**

а) Нократ;
б) Ык;
в) Чулман

**2.Сөйләм культурасы нәрсә ул?**

**а**)әдәби телнең язма һәм сөйләмә формадагы нормаларын үзләштерү;
б) тел белеменең тел нормаларын өйрәнүче тармагы;
в) кешеләрнең әдәпле сөйләшүе;
г) А һәм Б вариантлары.

**3.Җиңү мемориалы монументының авторы кем?**

а) Фирдәвес Ханов;
б) Әхсән Фәсхетдинов;
в) Бакый Урманчы

**4. Дәүләт гербының авторы кем?**

а) Тавил Хаҗиәхмәтов;
б) Рамазан Байтимеров;
в) Риф Фәхретдинов

**5. Кайсы җөмләдә стилистик хата бар?**

а) Бу галстук синең кайсы күлмәгең белән барыр икән?;
б) Гомерләр уза икән ул!;
в) Дәү әниебезнең урыны җәннәттә булсын!;
г) Ләкин мин боларны кайдан алыйм?

**6.** ***Татар телендә кайсы пар сүзләр юк?***

а) гыйбрәт – гыйбарәт;
б) тәкбир – тәгъбир;
в ) хуш – һуш;
г) тәэсир – тәкъсир.

**7. Җырлы – биюле уеннар**
а) “Ватык телефон” “Май чүлмәге,” “Кап та коп”;
б) “Сукыр тәкә”,  “Кәбестә”,  “Буяу сатыш”;
в) «Кәрия – Зәкәрия”, “Ак калач”, “Йөзек салыш”
**8.Кайсы  җөмләдә  стилистик  хата  бар?**
а) Тышта  ниләр  бар  икән?;
б) Храм  музейга  әверелдерелә;
в) Шомыртлар  чәчәк  ата;
г) Бәхет  дигәннәре  шулдыр  инде  ул!
**9.  “Ишеттем мин кичә берәү җырлый...” шигыренең исемен тап**
а)   “Милли моңнар”;
б)  “Бер татар шагыйренең сүзләре”
в)   “Киңәш”
**10.Аллы – гөле чәчәк ата безнең  җирләрдә генә,**
**Рәхәт тормыш, матур тормыш безнең илләрдә генә” юллары кайдан алынган?**
а)  җырлы – биюле уеннан;
б)   әкияттән;
в)   романнан
Җаваплар
1  2 3 4  5  6 7 8 9  10
в   г а в  а г  в  б  а   а
Бәяләү критерийлары:

| Дәрәҗә | балл |
|---|---|
| Югары | 10 |
| Уртача | 9 - 5 |
| Түбән | 4 әзрәк |

## Агымдагы  конторль

**Максат:**  Татар халык шагыйрьләре әсәрләре   мисалында  укучыларның сөйләм теле культурасын, сәнгатьле сөйләм күнекмәләренең камилләшү дәрәҗәсен билгеләү
**Контроль формасы:**  шигырь бәйгесе

**Шигырь бәйгесе**

| **Критерийлар** | **Түбән** | **Уртача** | **Югары** |
|---|---|---|---|
| дикция һәм тавыш белән идарә итү | тавыш көче түбән, күп авазларны дәрес әйтми | кайбер авазларны дөрес әйтми | Авазлар артикуляциясен яхшы тоемлый |
| сөйләүче образы | текстны  аңлау дәрәҗәсе бик түбән, әсәрдәге лирик геройның хис - кичерешләрен тоемламый | лирик  геройның хис – кичерешләрен аз дәрәҗәдә тоемлый | текстның образлы системасына үтеп керә, лирик геройның хис – кичерешләрен югары дәрәҗәдә  бирә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| гәүдә хәрәкәте | гәүдәсен матур тотмый, мимика, хәрәкәтләр урынсыз, аудиторияне сиземли алмый | Мимика, хәрәкәтләр югарлыгы өлешчә, аудитория белән аралашу өлешчә | мимика, хәрәкәтләр урынлы, аудитория белән аралашу көчле |

Бәяләү критерийлары:

түбән – 1 балл

уртача – 2 балл

югары – 3 балл

## СӘНГАТЬЛЕ ИТЕП СӨЙЛӘҮ ӨЧЕН ШИГЫРЬЛӘР

**Туган телем**

Асыл сүзләреңне, туган телем,
Биреп торчы миңа азга гына.
Бөтенләйгә түгел – вакытлыча,
Тик җитәрлек гомер азагыма.
Синнән алган һәрбер сүземне мин
Күз карасы төсле саклар идем.
Ул сүзләрнең затлыларын сайлап,
Дога итеп кенә ятлар идем.
Ул сүзләрне җырга әйләндергәч,
Мин кайтарып сиңа бирәчәкмен.
Исраф булмас ул сүзләрең миндә.
Җыры булыр алар киләчәкнең.
Әйтә алмыйм әле – ул сүзләрдән
Аз булса да дөнья үзгәрерме?
Тик югалтмам, туган телем, синнән
Алып торган асыл сүзләремне (Р.Миңнуллин).

**Тел**

“Тел, тел”, - дибез, тел нәрсә!
Әгәр телә белмәсә:
Бәгырьләрне телә-телә
Усал көлә белмәсә,
Йомшарып, тасма телләнеп
Җанга керә белмәсә?!
Телнең ачысы була,
Телнең төчесе була:
Ачысын да, төчесен дә
Татыр кешесе була.
Ачы тел – хак агайда,
Төче тел – ялагайда:
Төче тел бик кирәк була

Тәлинкә ялаганда.
Телнең тияге булмый,
Телнең сөяге булмый.
Никадәрле сөйләсә дә
Телнең сөяле булмый.
Эшләгәннең кулында,
Сөйләгәннең – телендә.
Телнең серен белим дисәң –
Хикмәт телнең төбендә.
Тел шигырьләр дә укый,
Тел вәгазьләр дә тукый,
Өнди ул әдәпкә дә,
Күндәм ул әләккә дә.
Ләчтит саткан да шул тел,
Дан тараткан да шул тел,
Тәнкыйтьченең авызында
Эшсез яткан да шул тел.
Тел елата, юата,
Матур уйлар уйлата,
Йә үрти, йә көлдерә,
Уңдыра йә бөлдерә.
Сөйдергән дә тел генә,
Көйдергән дә тел генә...
Тел шикелле универсал
Бу дөньяда бер генә.
Телең барында бер дә
Сүз әйталмый тилмермә:
“Телем – дошманым!”– дип әйтеп,
Телгә телең тидермә.
Уе юкның – теле юк,
Теле юкның – иле юк.
Илен санга санамаган
Телсездән дә тиле юк (Н.Арсланов).
**Туган тел турында бер шигырь**
И, кардәшем! Бер хаҗәтсез кайчак
Телне шундый бозып сөйлисең
Ил колагын хурлап, халыкның
Рухын рәнҗетәмен димисең!
Мескенләнмә, бакый гомер килгән
Тел байлыгын итмә кадерсез.
Бер уйласаң, илаһи бит, изге
Кеше әйткән аваз, һәрбер сүз!
Һич мәртәбә түгел телдә
Җиң очына карап сөйләшү.

Көчле, горур сөйләш! Кирәк икән,
Хаким телләр торсын көнләшеп!
Иренмә син, туган, туган телнең
Асыл байлыкларын ачарга.
Без ваемсыз булсак, чит-ят сүзләр
Хәзинәңне әзер басарга!
Ана телен ватып-бозып сөйләп,
Кешелегең генә төшә бит;
Корама тел, яман чир булып,
Яңа буыннарга күчә бит!
Күп телләрне белү- яхшы шөгыль,
Туган телең үги калмаса;
Җаның салып әйткән әткәң сүзен
Синең аша балаң аңласа.
Киләчәкнең башы – бүгенгедә.
Нинди шатлык картлык көнеңдә
Оныкларың сиңа рәхмәт әйтсә
Матур итеп татар телендә! (Р.Фәйзуллин).

**Ике канат**

Туган телем күп еллардан бирле
Чәчәк ата йөрәк түремдә.
"Әнкәй" дигән иң беренче сүзне
Мин әйткәнмен татар телендә.
Гашыйк булган сымак юлда егет
Җилдән җитез чапкан атына;
Мин гашыйкмын сиңа, туган телем,
Син чын байлык минем зәүкыма.
Газиз телем гасыр диңгезләрен
Кичә-кичә килгән ерактан.
Шушы телдә бәхет теләп илгә,
Җырларымны миргә яңратам.
Туган оясыннан аерылган кош
Канатына мәңге ял тапмый.
Туган телен яратмаган кеше
Башкаларның телен яратмый.
Заман миңа:"Югарыга мен!" – дип
Ике канат биреп үстерде.
Канатымның берсе – татар теле,
Икенчесе – бөек рус теле (Ә.Ерикәй).

**И туган тел**

И борынгы татар теле,
Кадерле туган телем.
Син минем көчле коралым,

Син миңа – акыл, белем.
Син шигърият кояшым,
Син гасырлар ялкыны,
Тарихлар ашыкмый аккан
Син туган тел аркылы.
Син халкымның һич суынмас
Кодрәтле кайнар каны,
Мәңге дә сафлыгын җуймас
Сүрелмәс бәллүр җаны.
И туган тел, и матур тел –
Ватаным кебек гали.
Әнием кебек кадерле,
Тормышым кебек гади (Р.Рәкыйпов).

**Туган тел**

И минем җандай кадерлем,
И җылы, тере телем!
Кайгылар теле түгел син,
Шатлыгым теле бүген.
Тик синең ярдәм белән мин,
Тик синең сүзләр белән
Уйларын йөрәккәемнең
Дөньяга әйтә беләм (Х.Туфан).

**Туган тел хакында**

Тел ачылгач, үз телеңдә әйтә алсаң: “Әни!” – дип,
Тел ачылгач, үз телеңдә әйтә алсаң: “Әти!” – дип, –
Күзләреңә яшьләр тыгылмас,
Туган телең әле бу булмас.
Соң минутта үз телеңдә әйтә алсаң: “Әни!” – дип,
Соң минутта үз телеңдә әйтә алсаң: “Әти!” – дип, –
Күзләреңә яшьләр тыгылыр,
Туган телең әнә шул булыр! (Зөлфәт).

## Йомгаклау контроле

## Проект яклау

**Проектның максаты**: укучылар үз исеме, туганнары, сыйныфташлары исемнәренең килеп чыгышын, мәгънәләрен ачыклау.

**Контроль формасы**: проект яклау

## “Исемең матур, кемнәр куйган?”

**Проектның бурычлары**: Гаилә әгъзалары, сыйныфташларның исемнәре турында мәгълүматлар һәм аларның фотографияләрен туплау. Аларның исемнәре нинди

мәгънә аңлатканын һәм ни өчен шул исемне кушуларын ачыклау. Проект эшен уңышлы башкарып чыгу.

**Проектның тибы:** комплексллы (иҗади, фәнни – эзләнүле).

Проектның сораулары:

Кеше исемнәре кеше өчен нинди әһәмияткә ия ?

Үзебезнең һәм иң кадерле кешеләребезнең исем мәгънәләрен беләбезме?

**Проект эшенең актуальлеге**. Бу проект эшендә үзебезнең гаиләдәге иң якын кешеләрнең, сыйныфташларның исем мәгънәләренә һәм шул исемнең кушылу тарихына игътибар бирелә.

1.Мәгълүмат белән эшли белергә.

2.Максат куярга.

3.Планлаштырырга.

4.Уйлау, фикерләү сәләтен үстерергә.

5.Белем дәрәҗәсен арттырырга һ.б.

“Тел сүз, исем-фамилия милләтнең йөзе, тылсымлы могҗизасы һәркемгә үз исем-күңеленә иң якын, иң кадерле исем-сүз”.

Гомәр Саттар-Мулилле

“ Кыз бала исемендә йолдыз балкышы яки чәчәк нәфислеге, ир-ат исемнәрендә кылыч чыңы һәм китап акылы чагылсын”.

Рәсул Гамзатов.

**Эзләнүләрнең нәтиҗәсе:** эзләнү, иҗади фикер йөртү юнәлешендәге исем кушу тарихы, исем мәгънәләренең нинди бай хәзинә икәнен аңлау. Эш барышында әдәби китаплардан, сүзлекләрдән файдалану, укытучы, әти- әни белән берлектә интернет аша күп мәгълүмат туплау. Проект эшен эшләгәндә укучы:

1. эзләнергә,
2. бирелгән эшкә җаваплы карарга;
3. куелган сорауларга җавап табарга өйрәнә.

**Кулланылган әдәбият:**

-Татарча-русча кеше исемнәре һәм фамилияләре сүзлеге, Татарстан китап нәшрияты, 2006 ел.

-Гомәр Саттар-Мулилле”Татар исемнәре ни сөйли”? “Раннур” нәшрияты 1998 ел.

- Гаиләдә өлкәннәр сөйләве.
- интернет ресурслар

| Критерийлар | Түбән | Уртача | Югары |
|---|---|---|---|
| Теманы аңлый һәм аңлата белү, ни өчен бу теманы сайлауны аңлата белү | Теманы аңлата алмый, ни өчен сайлавына аргумент китерә алмый | Теманы аңлый, ни өчен сайлавын ачык дәлилли алмый | Теманы аңлап, ни өчен сайлавын тулысынча дәлилләп сөйли ала |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Һәр бүлекнең кыскача эчтәлеген сөйли һәм үз фикереңне аңлата белү | Бүлекләрне логик фикерләп сөйләү дәрәҗәсе бик түбән | Бүлекләрне логик фикерләп сөйләү дәрәҗәсе буталчык, тиешле югарылыкта түгел | Һәр бүлекне югары дәрәҗәдә логик фикерләп, фикерләрен системага салып сөйләп бирә ала |
| Теманың билгеле бер эзлеклектә баруы, проект эшенең бердәм таләпләренә туры килүе | Проект бердәм таләпләргә туры килми, эзлеклеклек сакланмаган, фикерләр сөреше буталчык итеп бирелгән | Проект бердәм таләпләргә өлешчә генә туры килә, фикерләр сөрешендә ялгышлар бар | Проект бердәм таләпләргә тулысынча туры килә, фикерләр сөреше дөрес |

**Бәяләү критерийлары:**
түбән – 1 балл
уртача – 2 балл
югары – 3 балл

## КУЛЛАНМА ӘСБАПЛАР

*Педагог куллана торган әдәбият исемлеге:*


1. Педагогика. Под редакцией Л.И. Пидкасистого. – Москва:«Просвещение», 1999 ел.
2. Н.Г. Гәрәева, Н.В. Максимов, Ә.Ә. Зиятдиновна. «Тел белемнең ачкычы» - Казан: «Тат.кит.н.», 2002 ел.
3. Татар акылы. Фәнни редактор А.Г. Яхин. – Казан:- 2005 ел.
4. «Гасыр авазы» журналы №3/4 2001, №5, 7, 9, 2008 № 2/3 2002, № 3/4 2006 № 1/2 2005, №8, 9 №2012
5. Л.М. Низамов. Милли мәктәп, тәрбия нигезләре. – Казан: «Мәгариф», 2004 ел.
6. Гомуми мәгълүмат, күнегүләр, коммуникатив биремнәр, контроль тестлар Э.Н.Денмөхәммәтова, Г.Р. Мөгътәсимова Ә.Ш.Юсупова, Г.Ә.Нәбиуллина, Казан — 2009. Н.Г.
7. Татар акылы. Фәнни редактор А.Г. Яхин. – Казан:- 2005 ел.
8. «Гасыр авазы» журналы №3/4 2001, №5, 7, 9, 2008 № 2/3 2002, № 3/4 2006 № 1/2 2005, №8, 9 №2010, №7, 8 2012
9. Балалар фольклоры. Р. Ягфаров редакциясе. –Казан: «Фаннур», 1998 ел– 345 б.
10. Р.С. Немов. Психология. – Москва: «Владос», 2001ел - 462 б.
11. «Мәгариф» журналлары № 5-10,1998 ел, № 4-6, 1999 ел, № 7-9, 2000 ел, № 10-12, 2001 ел, № 3-5, 2002 ел, № 4-6, № 7-8, 2004 ел, № 3-4, 2005 ел, № 5-7, 2011ел.

12. Кол Гали «Йосыф китабы»  - Казан: «Тат.кит.н.», 2000 ел -1960 бит.
13. Р.К. Уразманова «Обряды и праздники татар Поволжья и Урала». – Казан: «Фаннур» - 2004 ел- 245 бит.
14. Бишек җырлары. – Казан: «Фаннур» - 2005ел-146 бит.
15. Татарско-русский учебный словарь под редакцией: Ф.А. Ганиева, И.А. Абдуллина, Ф.Ю. Юсупова  - «Фаннур», 1999ел-502 бит
16. Татар әдәбияты тарихы. – Казан: «Фаннур», 1-6 томнар, 2001ел-365 бит.
17. И.Рәми, Р. Даутов. Әдәби сүзлек. – Казан: «Тат.кит.н.», 2001ел- 402 бит.
18. Р. Нуриев. Татар драматургиясенең лингвистик поэтикасы. Казан. «Фаннур», 2002ел-296 бит.
19. Журнал «Казань» № 1-6, 1997 ел.

*Балалар һәм ата-аналар өчен тәкъдим ителә торган  кулланма әдәбият:*

29. Гомәр Саттар-Мулилле “Татар исемнәре ни сөйли?” Казан, “Раннур” нәшрияты,1998 ел.,

30.  Энҗе чәчтем-энҗе җыям. Бәетләр. Мөнәҗәтләр. Дастаннар. Татар халык җырлары. – Казан: «Мәгариф», 2000- 200 бит, 2001-148 бит, 2002-136 бит, 2004-206 бит

КУШЫМТА 1

## Методик материаллар

**Телдән сөйләмгә өйрәтү күнегүләре:**

1. Җөмләләрне укыгыз һәм сораулар куегыз.
2. Хикәянең ахырын уйлап бетерегез һәм сөйләгез.
3. Тормышыгызда булган кызыклы вакыйга турында сөйләгез.
4. Укылган текстның төп эчтәлеген 2-3 җөмлә белән әйтеп бирегез.

5.Күренекле язучыларның сөйләм һәм җөмлә турында әйткән фикерләрен укыгыз. Бу фикерләргә таянып, тел, сөйләм һәм җөмләгә хас үзенчәлекләрне аңлатыгыз.

а) Туган тел – Тукай теле, татар теле, татар әдәбиятыбызның теле. Менә Тукай теле нинди киң мәгънәдә кулланыла бездә... Бөтен язганнарыңның ахыр чиктә рухы бит телдә... (С. Хәким).

ә) Кирәк икән шагыйрь халык сөйләшендәге формаларны, җөмлә әйләнешләрен дә шигырьгә шул килеш алып куя, буйсынмаса, буйсындыра, тел аның ихтыярында, шигырь могҗизалар ярата...
(С. Хәким)

6. Җөмләләрнең урыннарын үзгәртеп, бәйләнешле сөйләм оештырыгыз.

а) Шомырт куагы тирәсендә бал кортлары очып йөри.
ә) Бал кортларының тату гөжләве, куанычлы бәйрәм ясап, аларның чәчәктән чәчәккә очып-кунып йөрүләре җанга рәхәт сала.
б) Шомырт чәчәк аткан.
в) Алар басынкы гына шатланып гөжлиләр.
г) Баскыч төбендәге тирәкнең баллы яфраклары кояшта ялтырап торалар.
д) Иртән явып үткән кояшлы яңгыр бал төшереп киткән.
е) Авылны хуш ис чорнап алган. (М. Юныстан)

7. Бирелгән җөмләдәге тыныш билгеләрен аңлатыгыз.

Һәр бала янына чүгәләп, каләмне ничек тотарга икәнен күрсәтте,
ә аннары безгә таныш булмаган яңа сүзләрнең мәгънәсен аңлатып бирде.

8.Теземнәрне сәнгатьле итеп укыгыз.Санау һәм йомгаклау бүлеген аерып әйтегез. Санау бүлегендә нинди синтаксик берәмлекләр тиңдәшләнеп килгән? Сөйләп бирегез.Тыныш билгеләренең куелышын аңлатыгыз.

Алтын- көмештән кыйбат,
Актык өлештән кыйбат,
Гәүһәр- якуттан кыйбат,
Бөтен шатлыктан кыйбат,
Энҗе- мәрҗәннән кыйбат,
Бөтен нәрсәдән кыйбат,
Туган ил һәм туган җир! (Ш.М.)

Язма сөйләмгә өйрәтү күнегүләре:

1. Җөмләләрне күчереп языгыз һәм җөмлә кисәкләре ягыннан тикшерегез. Калын хәрефләр белән бирелгән сүзләргә морфологик – синтаксик анализ ясагыз.

Колхозның **йөз егерме** баш умартасы бар иде. (Г.Б.) Көн аяз, **җилсез,** артык эссе дә түгел.

2.Тиңдәш кисәкләр кулланып, якын кешегезгә (әти- әниегез, дустыгыз, сыйныфташыгыз, туганыгызга) бәйрәм белән котлау тексты языгыз.

3.Җөмләләрне сүзтезмәләргә таркатыгыз. Сүзтезмәләргә анализ ясагыз Сүзне төрлечә әйтеп була. (М.Ю.) Ана телен оныткан- анасын да оныткан. (Ш.Г.)

4.Туры сөйләмле җөмләләрне кыек сөйләмгә әйләндереп языгыз.

а) Арадан берсе:

- Ә син үзең кая юл тотарга җыенасың, Сәет олан? – дип, кискен сорау бирде.

б) Берәү, капкага килеп:

- Кем ул анда вакытсыз чуалып йөри ?- диде. (К.Н.)

5. Диалогларны тулыландырыгыз. Җавапларны ким җөмләләр белән языгыз.

- Син бу сүзлекне кайдан алдың?
- ....
- Күптәнме?
- ...
- Анда башка сүзлекләр сатыламы?
- ...

6. Җыелыш, киңәшмә яисә конференциянең беркетмәсен языгыз.

7. Мәкальләрне укыгыз. Мәгънәсен аңлатыгыз. Сүз турында сез тагын нинди мәкальләр беләсез?

Сүз бер көнлек, тел гомерлек.

Авыз күрке - тел, тел күрке – сүз.

Сүзнең башыннан элек ахырын уйла.

Яхшы сүз балдан да татлырак.

Фонетика, графика, орфография, сүз басымы, логик басым, сөйләмнең мәгънәле кисәкләргә бүленеше, сүзнең язылышы һәм әйтелеше үзенчәлекләренә караган биремнәрдә берничә варианттан сайлап алу мөмкинлеге бирелә.

**1. Тәкъдим ителгән схемага, терәк сүзләргә таянып, әңгәмә жанрына характеристика бирегез.**

Терәк сүзләр: - көнкүреш темага; фәнни ачышлар турында; килешүләр төзү турында; сәяси темаларга...

- максат: килешүгә ирешү; килешмәү (үз фикереңдә калу); бурычлар: алган тәэсирләр белән бүлешү; үз фикереңне белдерү; элемтәдә тору, ярдәм алу...
- эшлекле, көнкүреш, фәнни, фәнни-популяр, публицистик, фәнни-публицистик ...
- катнашучылар саны: күзгә-күз; ике-өч зат белән; кешеләр төркеме белән; тамашачылар, тыңлаучыларга һ.б. исәпләнмәгән күзгә-күз якм кешеләр төркеме белән ...
- чиратлашу саклана (сакланмый); алдан билгеләнгән (билгеләнмәгән);
- каршы әйтешү чиратлашып бара (кыска яки озын); бер, ике һ.б. сөйләүченең репликалары өстенлек итә ...
- җөмләләр арасында пауза; җөмлә эчендә пауза; уйлану, икеләнү тудырган паузалар; паузаларны тутырып тору чаралары.

**2. Текстларны укыгыз. Тексттагы вакыйгаларга мөнәсәбәтегезне белдерегез. Биремнәрне үтәгез.**

1. ...Йомшак кына кар ява. Борынгы йортлар моңсу аклыкка күмелеп утыра. Фукс бакчасын үтеп, без текә яр кырыена килеп туктыйбыз. Кинәт кар явудан туктый, ак пәрдә күтәрелә. Аста - боз юрганын ябынган Казан елгасы.

- Казанның һәр карышы - тарих, - ди Диләрә. - Син үзеңнең нинди урында басып торганыңны беләсеңме? Унтугыз яшь... Очынып, яшәргә омтылган чак югыйсә... Ә ул, кесәсенә салкын револьвер тыгып, үз-үзен атып үтерергә дип нәкъ менә шушы урынга килә. Күз алдыңа китер, беркемгә билгесез Алексей Пешков, кар шыгырдатып, монда таба килә. Әгәр ул шунда төнге каравылчыны очратып тукталмаса, аның белән сөйләшеп тормаса... Ул киткән яктан яңгыраган револьвер тавышына, бәлки, төнге каравылчы бөтенләй игътибар да итмәгән булыр иде. Ул йөгереп килеп карый да, тиз арада извозчик табып, авыр яралы Пешковны больницага озата, соңыннан да янына килеп йөри.

- Бәхетле очраклылык.

- Киләчәктә Максим Горький булачак кешене үлемнән коткарып калганын башына да китермәгәндер каравылчы ул чакта.

- Кем икәне билгелеме аның?

- Мостафа Юнысов. Гап-гади бер татар агае. *(М. Галиев)*

2. Бер ел заводта мастер булып эшләгәч һәм заводның культура сараенда һәвәскәрләр белән мәж килгәч, аны үз янына цех башлыгы чакырып ала:

- Мастерларны без заводка ел саен йөзәрләп алабыз. Техникумнар аларны безгә, шөкер, күпме кирәк шулхәтле җитештерә. Укы син, туган, табигать биргән талантыңны җәберләмә.

Бу юлы консерваториядә, аның бәхетенәдер, Алмаз Монасыйпов очрый. Бик йомшак күңелле, бик йомшак тавышлы кеше бит инде ул. Пермь хәтле Пермҗнән кигән, күңелендә мең төрле ышаныч йөрткән егетне ул сабыр гына тыңлый, аннары әйтә:

- Леманга барырга кирәк сиңа, үскәнем. Альберт Семеновичка. Ул хәзер өендә. Өенә бар син аның. Студентларны ул өендә дә кабул итә, ди. Менә сиңа адресы, бар син аңа, иренмә.

Леман аны гап-гади каршылый, йомышын тыңлагач, болай ди:

- Утыр, уйна.

- Мин фортопианода уйнамыйм, бармаклар бик калын минем, клавишаларга кысыла. Әти дә, әни дә җир кешеләре иде, - дип акланмакчы була Имашев. - Мин фортепианода уйнамыйм, җырлап язам көйне.

- Ярый, алайса, җырла.

Мәсгут татарның ул чакта нык таралган көе "Шахта"ны балалайкада уйнарга өйрәнгән, "Скрипкада үзлегеңнән өйрәнү" китабын табып, нота язарга да "остарган" була инде.

- Карале, туганкай, синең бит тавышың бар. Менә сиңа язу, бар консерваториягә, Елена Абросимовага бирерсең моны. *(Г. Ахунов)*

**<u>Бирем</u>.**

1. Диалогларда аралашу кагыйдәләренең кайсылары исәпкә алынмаган?

2. Аралашучыларның аралашу барышында нинди хаталарына игътибар иттегез? Сез шуңа охшаш ситуацияләрдә үзегезне ничек тотар идегез? Үз вариантларыгызны тәкъдим итегез.

Әңгәмә алып барганда, сорау бирә белү осталыгы аеруча әһәмияткә ия. Көтелгән җавап характерыннан чыгып, сорауларны ачык һәм ябык төрләргә бүлеп йөртү кабул ителгән.

Ябык сорауларга әйе яки юк дип яки берничә сүз белән генә җавап бирергә мөмкин. Мәсәлән, "Сезгә ничә яшь?", "Сез кайда яшисез?", "Сез ничәнче мәктәпне тәмамладыгыз?", "Сезгә эшегез ошыймы?" һ.б. Шулай ук -мы//-ме кисәкчәле сорау җөмләләр дә, фигыльнең юклык формасы һәм бит кисәкчәсеннән яки -мыни//-мени кисәкчәләреннә торган төрләре дә, мәсәлән, "Сез алай уйламыйсыз бит, шулаймы?", "Сез китәргә теләмисезмени?" кебек сораулар да ябык сорау вариантларын тәшкил итәлә. Эшлекле әңгәмә вакытында җавабы ачык күренеп торган мондый төр ябык сорауларны альтернатив вариантлары белән алыштыру дөресрәк булыр, мәсәлән, "Сез укуыгызны дәвам итергә теләр идегезме?" "Сез ничек уйлыйсыз: бу фикер коллектив тарафыннан яклау табырмы?". Мисаллардан күренгәнчә, ябык сораулар төгәл, кыска җаваплар көтелгәндә бирелә.

Ачык сораулар сорау алмашлыкларына нигезләнеп төзелә һәм җавап бирүчегә ирек күбрәк бирелә, мәсәлән, "Сез ни өчен безнең оешмага эшкә урнашырга телисез?", "Сез нәрсәне күз алдында тотасыз?" һ.б. Мондый төр сорауларга җавап бирүче үзенең җавабын мәсьәләне аңлавыннан чыгып бирә. Шуңа күрә ачык сораулар катлаулы, буталчык мәсьәләләрне хәл итү максатыннан яки әңгәмәдәшеңнең теге яки бу мәсьәләгә мөнәсәбәтен ачыклау ниятеннән чыгып бирелә.

Сорауларга салынган эчтәлектән чыгып, аларны ике төркемгә бүлергә мөмкин: фактлар (мәгълүматлар) турындагы һәм фикерләр, теләкләр турындагы сораулар.

Фактлар (мәгълүматлар) турындагы сораулар билгеле бер вакыт һәм урын аралыгында башкарылган эшләрне, вакыйгаларны ачыклау өчен кулланыла, мәсәлән: "Сез кичә җыелышта булдыгызмы?", "Сез ничәнче елда мәктәпне тәмамладыгыз?", "Бу сезнең улыгызның фотосымы?". Гадәттә мондый сорауларга җавап бирү бернинди авырлык та тудырмый, шуңа күрә андый сораулар әңгәмәнең башында бирелеп, әңгәмәнең уңышлы башлануына ярдәм итә. Күпчелек очракта мондый сораулар ябык характерда була.

Фикерләр, теләкләр турындагы сорауларга җавап алу шактый авыр, чөнки кешенең теләк-ниятләре, теге яисә бу әйберләргә мөнәсәбәте төгәл, ачык, анык та һәм киресенчә дә булырга мөмкин. Шуңа күрә мондый төр сорауларны төзүгә аеруча игътибарлы булырга кирәк, аларда бәяләү, фикереңне тагарга тырышу чагылмаска тиеш, мәсәлән, "Сезгә шул кызыкмы?" дип түгел "Сезнең бу мәсьәләгә карашыгыз нинди?", яки "Сезнең бу мәсьәләгә карашыгызны белергә теләр идем" кебек вариантларны тәкъдим итү дөресрәк булыр иде.

Әңгәмәдәшең каршына куела торган сораулар функцияләренең төрлелеге белән дә аерылалар. Бер төр сораулар өстәмә мәгълүмат алу, булганнарын тикшерү, ачыклау, төгәлләү функциясен башкара. Икенчеләре әңгәмә барышында туган киеренкелекне

йомшарту, әңгәмәнең юнәлешен күзәтү, бер темадан икенче темага күчүгә ярдәм итү өчен бирелә, аларны функциональ-психологик сораулар дип йөртәләр.
Функция төрлелеген чагылдыручы сорауларга контоль, аныклаучы һәм зондируюәие сораулар керә.
Контроль сораулар алынган җавапның чынбарлыкка, дөреслеккә ни дәрәҗәдә туры килүне чагылдыра. Мисал өчен, әңгәмә башында сез әңгәмәдәшегезгә аның эшеннән ни дәрәҗәдә канәгать булуын ачыклау өчен сорау бирдегез, ди. Шуннан соң берничә сорауга җавап алгач, сез беренче контроль соравыгызны биреп карыйсыз: "Сез мөмкинлек булса, башка эшкә күчәр идегезме?", аннан соң икенче контроль сорау килергә мөмкин: "Әйтик, ниндидер сәбәпләр аркасында, сез вакытлыча эшләмисез, ди. Шул вакытта элек эшләгән урыныгызга чакырсалар, кире кайтыр идегезме?" һ.б. Алынган өч төрле җавапны чагыштырп карап, әңгәмәдәшегезнең сезнең белән ни дәрәҗәдә ихлас сөйләшүен билгеләве кыен түгел, билгеле.
**3. Теләсә кайсы сөйләшүне ( мәсәлән, гаиләдә иртәнге аш вакытында сөйләшүне яки җитәкченең үзенең ярдәмчеләре белән эшкә кагылышлы мәсьәләләрдә сөйләшеп утыруын) әңгәмә дип атарга мөмкинме?**
Әңгәмәгә нигезләнеп төрле жанрлар барлыкка килә, шуларның иң әһәмиятлесе интервью. Әңгәмә-интервьюның, катнашучы кешеләр исәбеннән чыгып, түбәндәге төрләре күзәтелә:
- бер катнашучы (сорау бирүче) - бер катнашучы (җавап бирүче);
- бер катнашучы(сорау бирүче) - берничә җавап бирүче;
- берничә сорау бирүче - берничә җавап бирүче.

**4. Үзегез темалар уйлап әңгәмә-интервьюлар оештырыгыз һәм дәрестә шуның үрнәкләрен күрсәтегез.**
*Эшлекле әңгәмә*
Эшлекле әңгәмә - рәсми шартларда рәсми зат белән аралашу ул. Эшлекле аралашуның түбәндәге гамәли максатлары була:
- кирәкле мәгълүмат алу яки алмашу;
- партнерларны кызыксындырган мәсьәләләр буенча килешүгә килү;
- партнерыңны сайланган юлның, килешүнең аның өчен файдалы, уңышлы булуына ышандыру һ.б.
- үзеңнең статусыңны саклаган хәлдә эшлекле мөнәсәбәтләр, контакт урнаштыру.

**5. Әңгәмә темасын, аның конкрет бурычларын һәм эшне оештыруны чагылдыручы җөмләләрне тиешле тавыш белән укып чыгыгыз.**

| Әңгәмәнең тексты | Комментарийлар, сорау-биремнәр |
|---|---|
| **Киноменеджер**. Хәерле иртә. Сезнең белән кабат очрашуыма шатмын.<br>Минем сезнең белән экраннарга чыгарылган фильмның уңышын тәэмин итү турында сөйләшәсем килә. Ялгышмасам, фильм шактый уңышлы | Әңгәмәнең инициаторына эшлекле элемтә һәм җылы мөнәсәбәтләр урнаштыру гаять әһәмиятле.<br>1. Сөйләшүнең түбәндәге моментларын билгеләп китик:<br>• әдәпле итеп исәнләшү; |

| | |
|---|---|
| килеп чыккан... Сез ниндирәк фикердә? Минемчә, безгә сөйләшүне рекламадан башларга кирәктер. Шуңа күрә башта фильмның кемгә күбрәк ошаячагын, тамашачысы кем булачагын фаразлыйк, шуннан чыгып, аны кем каршында рекламалавыбызны һәм уңышка ирешү өчен нәрсә эшләргә кирәк булачагын билгеләргә тырышырга кирәктер дип уйлыйм // Сез минем фикерем белән килешәсезме?// <br> **Әңгәмәдә катнашучылар**. Әйе. Килешәбез. ( Килешүләрен белдереп баш кагалар.) <br> **Киноменеджер.** Сез тамашачының зәвыгын, таләпләрен яхшы беләсез... моңарчы чыккан фильмнарның да уңышларын фаразлаганыгыз булды... Шуңа күрә сезнең һәрберегезнең фикерен ишетергә теләр идек. | • аудиториягә мөрәҗәгать итү;<br>• уртак фикергә килүгә теләк булу;<br>• башкаларның фикере белән кызыксыну.<br><br>2. Сорау җөмлә алдыннан һәм аннан соң килгән зур пауза // нинди максатка хезмәт итә?<br>3. Текстта тагын паузалар кайда һәм ни өчен ясалган? |

**6. Текстны укыгыз. Телефоннан сөйләшү кагыйдәләренә карата үз фикерегезне әйтегез. Әңгәмә//бәхәс оештырыгыз.**

*Телефоннан сөйләшә беләсезме?*

Бу сорау, беренче карашка, бик сәер яңгырый. Ләкин "Мин кая эләктем?", "Кем әле бу" дип башланган әңгәмәләрне еш ишетергә мөмкин. Килешәсездер, бу заман кешесен бизәми торган сөйләшү. Шуңа күрә, телефон куллануның кагыйдәләрен белү кирәк.

Әгәр эшегезгә шалтыратсалар, иң элек үзегез яки оешмагызның исемен атагыз. Ә өегездә "алло" дию дә җитә.

Эш буенча сорауларыгыз булса, үзегез белән таныштыру һәм "Гафу итегез, мин кем белән сөйләшәм?" дип сорау урынлырак булыр.

Кемнеңдер эш урынына шәхси мәсьәлә буенча шалтыратсагыз, сүзне мөмкин кадәр кыскарак тотарга тырышыгыз.

Әгәр телефон уңайсыз вакытта (җыелыш яки башка чара барган чакта) шалтыраса, трубканы күтәргәч тә кире куярга ашыкмагыз. Бу очракта "Җыелыш бара, соңрак шалтыратыгыз", - дип әйтергә кирәк.

Әңгәмәне өзеп торырга туры килсә, әз генә көтегез дип алдаганчы (күп очракта бу шулай була да), "Мин соңрак кабат шалтыратырмын", - дию файдалырак. Ләкин сүз биргәнсез икән, аны үтәргә дә онытмагыз!

Кем беләндер күрешеп сөйләшәсегез булса, телефон аша очрашу вакытын һәм урынын билгеләү белән чикләнегез.

Телефоннан сөйләшкәндә тыныч булыгыз, авазларны ачык әйтергә тырышыгыз.
Үзегез шалтыраткан очракта, әңгәмә өчен җаваплылык тоегыз. Сөйләшүне үзегез кирәк дип тапкан вакытта төгәлли аласыз.
Өй телефонына сәгать 9 дан иртәрәк, 22.00 сәгатьтән соңрак шалтыратмаска тырышыгыз.
Озакка сузылырдай сөйләшүне башлаганчы, әңгәмәдәшегезнең сезне тыңларга вакыты булу - булмавы белән кызыксыныгыз. *("Татарстан яшьләре")*

**Биремнәр.**
*1. Телефоннан сөйләшүдә кулланылырга мөмкин булган тәгъбирләрне файдаланып төрле оешмалар белән сөйләшү ситуациясен уйнап күрсәтегез.*
Сезгә ярдәм итә аламмы?
Мин ... белән сөйләшә аламмы?
Минем ... белән сөйләшәсем килә иде?
Мин сезне ... белән тоташтырам.
Бераз көтегез
Соңрак шалтырата алмассызмы?
Мин хәбәр калдыра аламмы?
*2. Бирелгән телефоннан сөйләшү үрнәкләренә мөнәсәбәтләрегезне белдерегез.*
1 нче үрнәк.
**Сәркәтип:** Галеев офисы.
**Ахунов:** Мин Галеев белән сөйләшә аламмы?
- Бер генә секунд. Трубканы куймагыз. Хәзер карыйм, урынындамы?
Бер минуттан соң
- Тыңлыйсызмы? Гафу итегез, Галеев урынында түгел. Ул конференциядә булырга тиеш. Әмма берничә минуттан кайтып җитергә тиеш. Хәбәр калдырырга телисезме?
- Әйе. Сез аңа әйтә алмассызмы, төшке ашка кадәр миңа шалтыратсын әле. Минем исемем Альберт Ахунов.
- Яхшы, Ахунов әфәнде. Мин язып куям. Ә ул Сезнең телефон номерыгызны беләме?
- Әйе. Мин аңа бер - ике көн элек шалтыраткан идем.
- Яхшы. Хушыгыз.
- Хушыгыз.
2 нче үрнәк.
**Сәркәтип:** Алло, Мелита офисы.
**Шакиров:** Исәнмесез. Минем исемем Марат Шакиров. Мин "Элеком" компаниясеннән. Мине Билалов әфәнде белән тоташтыра алмассызмы?
- Гафу итегез, ул биредә түгел. Нинди сорау буенча?
- Бу бик мөһим эш. Мин "Элеком" вәкиле. Без яңа продуктны җитештердек һәм Билалов әфәнде карасын дип ...
- Шакиров әфәнде, продуктның мәгълүматларны электрон почта ша җибәрегезче.
- Минем Билалов белән турыдан - туры сөйләшәсем килә иде. Нинди вакыт яхшырак булыр икән?
- Бер көннән соң шалтырата аласыз.

- Рәхмәт. Сау булыгыз.

3 нче үрнәк.
**Хафизов:** Минем исемем Ренат Хафизов. Менеджер белән тоташтыра алмассызмы?
**Сәркәтип:** Урынында түгел. Бераз көтегез.
- Яхшы.
- Гафу итегез, ул дүшәмбе көнгә кадәр булмый.
- Кайткач, миңа шалтыратсын, дип әйтә алмассызмы?
- Яхшы.

4 нче үрнәк.
**Сәркәтип:** Хәерле көн. "Элекон" компаниясе. Мин сезгә булыша аламмы?
**Зарипов:** Исәнмесез. Минем исемем Айдар Зарипов. Минем Матвеев белән сөйләшәсем килә иде.
**С:** Трубканы куймагыз, Зарипов әфәнде. Тоташтырам.
*Сәркәтип җитәкче белән тоташтыра.*
**Матвеев:** Алло!
С: Айдар Зарипов Сезне көтә.
М: Тоташтырыгыз.
*Сәркәтип Зарипов белән тоташтыра.*
М: Исәнмесез, Зарипов.
З: Исәнмесез Матвеев әфәнде. Эшләр ничек бара?
М: Яхшы, рәхмәт. Ә сезнең?
З: Минем дә яхшы. Мин сезгә очрашу хакында шалтыратам.
М: Әйе. Мин Сезне бер сәгатьтән соң көтәм.
З: Рәхмәт.

*4. Диалогларны татарчага тәрҗемә итегез.*
1 нче диалог.
**Сәркәтип:** Алло! Офис Латыпова. Чем могу помочь?
**Каримов:** Я бы хотел поговорить с Латыповым.
- Одну минуточку. Не вешайте трубку. Я узнаю, здесь ли он.
- Хорошо. Спасибо.
- Извините, но Латыпова на месте нет. Он будет здесь через два часа. Не хотите ли вы ему что- нибудь передать?
- Нет. Спасибо. Я снова позвоню завтра в это же время.
- Ваше имя и фамилия?
- Тимур Каримов. Я из компании «Нурлат - нефть».
- Хорошо. Я думаю, Латыпов будет в офисе завтра в это время.
- Спасибо. До свидания.

2 нче диалог.
А: Доброе утро. Компания «Элекон». Чем могу помочь?
Б: Здравствуйте. Моя фамилия Исмагилова. Я бы хотела поговорить с Камаловым.

А: Пожалуйста, не кладите трубку. Я вас соединяю.

*5. Чиратлап телефоннан сөйләшүдә катнашасыз. Беренче укучы А биремне, икенче укучы Б биремне карый.*
**Бирем А:** Сез Хафизов(а) әфәнде (ханым) булырсыз.
- Сез үткән елда Камалов(а) әфәнде (ханым) белән ярминкәдә очраштыгыз. Ул сезнең продукциягә заказ бирү тәртибе белән кызыксынды.
- Шәһәрдә булганда аңа шалтыратыгыз һәм киләсе дүшәмбе көнне кичке ашка чакырыгыз.
- Аның торган урынына якын булган берәр ресторан турында сорагыз.
- Ресторанның нинди булуын һәм үзәк тимер юл станциясеннән анда ничек җәяү барасын белешегез.
- Өстәлгә сәгать ничәгә заказ бирергә икәнен сорагыз.
**Бирем Б:** Сез Камалов(а) әфәнде (ханым) буласыз, үзегезнең фирмага запас частьләр алучы.
- Сез Хафизов(а) әфәнде (ханым) белән үткән елда үзегезнең шәһәрдә ярминкәдә күрештегез. Ул сезне кызыксындырган продукция белән эш итә. Ләкин сез аның турында шул вакыттан бирле бернәрсә дә ишетмәдегез.
- Киләсе дүшәмбе көнне кичен сез буш, әмма сәгать алтыга офиска кайтырга тиешсез.
- Сездән ресторан турында сорасалар, сез берәр яраткан урынны тәкъдим итегез.

*6. Мобиль телефоннарыгызны татарча мактап, реклама өчен диалог әзерләгез.*
*7. Бирелгән аралашу ситуацияләренең кайсында нинди стиль сакланырга тиешлеген аңлатып китегез. Коммуникациянең бу төрләре кайчан, кемнәр арасында күзәтелә?*
- халык алдында чыгыш ясау,
- лекция,
- рәсми хәбәр,
- пациентның табиб белән сөйләшүе,
- укучының укытучы белән сөйләшүе,
- интервью бирү,
- пассажирларның автобуста сөйләшеп барулары,
- сатып алучының сатучы белән сөйләшүе,
- дуслар арасындагы әңгәмә,
- төшке аш вакытында сөйләшү.

*8. Китап сөйләме һәм гади сөйләм теленә нигезләнгән телевизион тапшыруларны аерып күрсәтегез һәм әлеге сайланышны аңлатыгыз.*
- "Яңалыклар",
- "Хәерле иртә",
- "Сәяхәтчеләр клубы",
- "Мәгәр" ("Однако"),
- "Парламент сәгате",
- "Хайваннар дөньясында".

*9. Җөмләләрне әдәби нормага җавап бирерлек итеп төзеп языгыз. Көнкүреш сөйләм теленә хас үзенчәлекләрне билгеләгез.*

Миңа баш авырткannan. Биш сумга шәһәрнекен. Эт белән сезнең арттан? Хәзер җиңсез модада. Бау аркылы сикерә/ оныгым. Каршыда гына яши/ пенсиягә китте. Иртәгә матурын киям. Тиздән выпускной, аннан соң вступительныйлар/ ужас! Тавышсыз училищега алмыйлар. Балада температура. Икенчесен дә бирә алмаган. Машинага алып тордык.

*10. Түбәндәге сүзтезмәләр сөйләм телгә хас булган нинди үзенчәлекләрне ассызыклыйлар:*

- китапча сөйли;
- йоклатырлык итеп сөйли;
- теле бик ярлы;
- язылганча сөйли;
- гади сөйләшә.

11. Чит телдән кергән сүзләрнең татар телендәге синонимнарын китерегез, синонимнары булмаганда аңлатмасын бирегез:

1. респондент, инвестор, прерогатива, квота, аудитор, альянс, эксклюзивный, аппелировать, секвестр;
2. мораторий, менталитет, адекватный, идентичный, антагонизм, инфантильный, индифферентный;
3. амбиция, анализ, библиотека, вердикт, вестибюль, вокальный, детальный, диалог, импорт, лексикон, мемуары, пунктуль, реставрация, фауна, флора, экспорт

*Үрнәк: респондент - анкета сорауларына җавап бирүче кеше.*

**”Тел күрке - сүз” өстәмә белем бирү программасының методик тәэмин ителеше**

1нче ел укыту

| № п/п | Бүлек | Шөгыль формалары | Укыту-тәрбия процессын оештыру алымнары һәм методлары | Күрсәтмәлелек | Техник җиһазлау | Нәтиҗә ясау формалары |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Кереш өлеш | куркыныч сызлык кагыйдәл әре белән танышу, | сөйләм, күрсәтмә-лелек | сораулар тупланган анкета бланклары | ноутбук, интерактив такта | әңгәмә, сораштыру |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | фикер алышу | | | | |
| 2 | Туган телем-татар теле | семинар дәресләр | өлешчә эзләнү, чагыштыру, тыңлап аңлау | дәфтәрләр, әзер шаблоннар, трафаретлар, “Тел – фикерләр чыганагы” папкасы материаллары | компьютер, интерактив такта | аралашу |
| 3 | Татар теленең сүз байлыгы хәзинәсе | лекция, дәрес - конференция | сөйләм, аудио, видеоматериалларга күзәтү ясау | дәфтәрләр, “Идел”, “Мирас”,“Гасырлар авазы” журналары, дидактик материал тупланаган карточкалар | мультмедея проекторы, интерактив такта | үзлектән эш |
| 4 | Татар орфографиясенең кыен очраклары | традицион дәресләр, дәрес - дискуссия | өлешчә эзләнү, анализ | газета - журнал мәкаләләре, мультмедия материаллары, видеоязмалар | компьютер, интерактив такта | Хаталарны төзәтү |
| 5 | Сәнгатьле сөйләм күнекмәләре | конкурс | сөйләм, күрсәтмәлелек, чагыштыру | шигырь җыентыклары аудиоязмалар, видео чыгышлар, | мультмедея проекторы, интерактив такта | мини- тест |
| 6 | Аралашу әдәбе. Телдән яки язма аралашу | эшлекле уен, традицион дәресләр | сөйләм, күрсәтмә-лелек, фикер алышу, фронталь | әзер шаблоннар альбомнар, этно-лингвистик материаллар | мультмедея проекторы, интеракти | иҗади бәйге |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | эш | презентация | в такта | |
| 7 | Иҗади күнегүләр. Тәрҗемә эше белән шөгыльләнү | традицион дәресләр, лекция, семинар | сөйләм, өлешчә эзләнү,тыңлап аңлау | презентация, видеоматериал, альбом, фотографияләр | компьютер, интерактив такта | Карточкалар белән эш |
| 8 | Хәзерге заман эшлекле татар теле | традицион дәресләр, лекция, семинар | сөйләм, күрсәтмә-лелек, фикер алышу, парларда эш | газета – журналлардан мәкаләләр, рәсем-фотолар, видеопрезентацияләр | мультимедия проекторы, интерактив такта | үзлектән эш |
| 9 | Татар халык иҗаты. Аның жанрлары | иҗади очрашулар, экскурсия, репетиция, концертлар | инервью, өлешчә-эзләнү | күрсәтмәлелек, видеоматериаллар, халык иҗаты тупланган җыентыклар (әкиятләр, бәетләр, ривятьләр, дастаннар һ.б.) | мультимедия проекторы | иҗади бәйге |
| 10 | Татар балалар язучылары | эшлекле уен, традицион дәресләр. лекция | сөйләм, фикер алышу, анализ, чагыштыру | папкаларга тупланган материаллар, ауди-видеоматериаллар, фотографияләр | компьютер, интерактив такта | аралашу |
| 11 | Йомгаклау | иҗади бәйге | сөйләм, күрсәтмә-лелек, өлешчә-эзләнү | сораулар тупланган тест бланклары | компьютер, интерактив такта | иҗади эш |

2нче ел укыту

| № п/п | Бүлек | Шөгыль формалары | Укыту-тәрбия процессын оештыру алымнары һәм методлары | Күрсәтмәлелек | Техник җиһазлау | Нәтиҗә ясау формалары |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Кереш дәрес. Куркынычсызлык кагыйдәләре бәлән танышу | куркынычсызлык кагыйдәләре белән танышу | сөйләм, күрсәтмәлелек | тест һәм анкета бланклары | ноутбук, интерактив такта | тест |
| 2 | Татар милләтенең йолалары | лекция, дискуссия | сөйләм, күрсәтмәлелек, өлешчә эзләнү | дәфтәрләр, газета – журнал мәкаләләре, папка материаллары | мультмедея проекторы, интерактив такта | аралашу |
| 3 | Балалар фольклоры | сәхнәләштерелгән уеннар, актерлык осталыгы күнегүләре | сөйләм, үрнәк буенча эшләү, видеороликлар карау, анализлау | “Сабантуй”, “Салават күпере”, “Аргамак” газета - журналлары, видеопрезентацияләр | мультмедея проекторы, интерактив такта | мини - тест |
| 4 | Татарстан-минем республикам | блиц – турнир, традицион дәресләр | сөйләм, фикер алышу, фронталь эш | әзер шаблоннар, трафаретлар | компьютер, интерактив такта | үзлектән эш |
| 5 | К. Насыйриның педагогик эшчәнлеге | лекция, семинар дәресләр | энциклопедик материаллар белән танышу, видеоматериаллар | газеталардан мәкаләләр, альбомнар, фоторәсемнәр , видеопрезентация | мультмедея проекторы, интерактив такта | карточкалар белән эш |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | күрсәтү | | | |
| 6 | Иҗади күнегүләр Тәрҗемә эше белән шөгыльләнү | иҗади очрашу, экскурсия, әдәби - музыкаль салон | сөйләм, күрсәтмәлелек, өлешчә эзләнү | аудиоязмалар, видеочыгышлар, “Моңлы сазым” альбомы, | мультмедея проекторы, интерактив такта | иҗади бәйге |
| 7 | Тел – матурлык ачкычы | традицион дәресләр, дисскуссия, бәхәс | сөйләм, фикер алышу, үрнәк буенча эшләү | презентация, видеоматериал, альбом, фотографияләр | компьютер, интерактив такта | үзлектән эш |
| 8 | Халкыбызның күңел бизәкләре – кул эшләре | эшлеклеуен, традицион дәресләр, лекция | сөйләм, күрсәтмәлелек, фикер алышу, фронталь эш | газета – журналлардан мәкаләләр, рәсем, әзер шаблоннар, трафаретлар | мультимедея проекторы, интерактив такта | бирем |
| 9 | Түбән Кама-туган төбәгем | диспут, традицион дәресләр, очрашулар | чагыштыру, фикер алышу, бәхәс | папкаларга тупланган материаллар, ауди-видеоматериаллар, фотографияләр | мультимедея проекторы | карточкалар белән эш |
| 10 | Гаилә тарихы-халкыбыз тарихы | иҗади очрашулар, репетиция, концертлар | сөйләм, аудиоязмалар тыңлау, видеочыгышлар карау | күрсәтмәлелек, видеоматериаллар, | мультимедея проекторы | иҗади эш |
| 11 | Йомгаклау | иҗади бәйге | өлешчә эзләнү | сораулар тупланган тест бланклары | компьютер, интерактив такта | тест |

3нче ел укыту

